www.assalam.ru
www.islamdag.ru
assalamweb@gmail.com

12+

# ӘС-СӘЛӘМ

ДИН-МӘГЪРИФӘТ ГАЗЕТАСЫ

Бәясе иркле

АЛЛАҺЫ ТӘГАЛӘГӘ МАКТАУЛАР БУЛСЫН!

Рабигыләүвәл 1438 ел. 1994 нче елдан бирле бастырыла. № 1 / 15 декабрь 2016 ел.

# Рабигыләүвәл башлануы белән котлыйм!

**КАМИЛ ХӘЗРӘТ СӘМИГУЛЛИН**

**ТАТАРСТАН МӨФТИЕ**

**Әссәламү галәйкүм вә рахмәтуллахи вә бәрәкатүһ!**

**Мөхтәрәм дин кардәшләребез!**

Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте һәм шәхсән үз исемемнән барлык мөселманнарны да исламдагы иң күркәм айларның берсе - рабигыләүвәл башлануы белән ихластан котлыйм!

2016 елның 30 ноябрендә мөселман календаре буенча өченче ай – рәбигыләүвәл ае башлана. Аны халыкта Мәүлид ае дип йөртәләр.

Мәүлид – туу, туган вакыт мәгънәсен аңлата. Бу айда Мөхәммәд пәйгамбәр (салләллаһү галәйһи вә сәллам) дөньяга килгән.

Аллаһы Тәгаләнең сөекле рәсүле, ахырзаман пәйгамбәре Мөхәммәд (салләллаһү галәйһи вә сәлләм) туган көне - рабигыльәүвәл аеның 12 нче көне. Мөселманнар 11-12 нче көннәр арасын Мәүлид киче буларак билгеләп үтәләр.

Мөхтәрәм дин кардәшләрем! Рәбигыләүвәл – Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтен искә төшерү ае.



Коръәни-Кәримдә әйтелә:

«(Ий, Мөхәммәд) Без сине бары тик рәхмәт билгесе итеп галәмдәге халыкларга күндердек» («Әнбия (Пәйгамбәрләр)» сүрәсенең 107 нче аяте).

Раббыбызның Мөхәммәд Пәйгамбәрне үзенең илчесе - рәсүле итеп җибәрүе – безгә күрсәткән иң зур рәхим-шәфкате.

Дин кардәшләребез рабигыләүвәл ае дәвамында мәчетләрдә, өйләрдә Сөекле Пәйгамбәребезне олылап вәгазьләр укыйлар, мөнәҗәтләр башкаралар, догалар кылалар.

Дини мәҗлесләр оештырып салаватлар әйтәләр. Салават ул - Пәйгамбәребезне мактау дигән сүз.

Раббыбыз «Әхзаб» сүрәсенең 56 нчы аятендә безгә Пәйгамбәребез салләллаһү галәйһи вә сәлләмгә карата салаватлар әйтергә боера:

«Аллаһ үзе вә фәрештәләре Пәйгамбәргә салават әйтәләр, ий мөэминнәр, сез дә Пәйгамбәргә салават әйтегез һәм сәлам әйтегез» («Әхзаб / Гаскәрләр», 33:56).

Аллаһы Тәгалә күрсәткән тугры юлны өйрәтүче Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһү галәйһи вә сәлләм сөннәтенә ияреп, аның тормышыннан үрнәк алып яшәргә, Раббыбызның рәхмәтенә һәм ризалыгына ирешергә насыйп итсен!

Мәүлид аенда Пәйгамбәребез салләллаһү галәйһи вә сәлләмгә салаватлар багышларга, бергәләп догалар кылырга язсын!

НӘСЫЙХӘТ

## Мәчет әдәбе

Татар халкында: «Кунак булсаң – тыйнак бул», дигән мәкаль бар. Берәр кешегә кунакка барырга уйладык исә – әзерләнәбез. Чиста, матур киемнәр киябез, күчтәнәч алып барабыз. Килеп җиткәч тә ишеген аяк тибеп ачмыйбыз. Эчкә үткәч үзебезне тыйнак тотарга тырышабыз, хәтта якын кешебезгә килсәк тә. Кешеләрнең йорт-җиренә карата шундый мөнәсәбәттә булабыз икән, Аллаһы Тәгаләнең йортлары – мәчетләрдә дә үзебезне тиешенчә тоту кирәк. Чөнки бәйтулла – Аллаһы Тәгаләнең йорты. Ә мәчеткә килгән һәр кеше – Раббысының кунагы.

БИТ 6

# Кол Шәриф мәчете

ИНСАН ТАВИЛЕВ

«Мәчет Казаннан егерме чакрым ераклыгындагы бик зур, бик куе, бик иске урман эчендә салынган, бинасы да ике йөз мең кадәр кеше сыйдырырлык дәрәҗәдә зур, бик нык, бик садә, татар инженер-архитекторларының берсе тарафыннан шул мәчет өчен генә уйлап чыгарылган архитектура стилендә ясалган иде. Бу мәчет күргән кешеләрдә бертөрле дәһшәт, куркыту, өмет һәм садәлек тойгылары уята һәм үзенең йөзләрчә ел яшәгән карт агачлар арасында, махсус эшләнми калдырылган урман эчендәге күренеше белән бертөрле сер-рият кәсеп итә иде. Егерменче гасыр уртасының бу мәчете дөнья зиннәтеннән иң буш бер җир иде ки, халык зиннәт һәм дөнья тереклегеннән туйган минутларында, дөнья белән мөнәсәбәтсез бер тереклек эзләгән көннәрендә, чын ихласлары белән монда киләләр иде».
Фатыйх Әмирхан «Фәтхулла хәзрәт». 1910 ел



Кол Шәриф мәчете

Татар халкының мәшһүр улы Фатыйх Әмирхан «Фәтхулла хәзрәт» повестендә «өмет һәм садәлек тойгылары уята» торган мәһабәт мәчетне Казаннан читтәрәк урнашкан итеп тасвирлый. Әдипнең хыяллары бер гасырдан соң диярлек тормышка аша. Алай гына да түгел, күркәм даны чит илләргә дә таралырлык гыйбадәт йорты бүген Татарстан башкаласының нәкъ үзәгендә – Казан Кирмәнендә балкып тора. Сүз, әлбәттә, Кол Шәриф мәчете турында.

Казан ханлыгын яулап алган чакта җимерелгән мәчетне яңадан торгызу фикере 1990нчы елларның башында ук яңгырый башлый.

Динсезлек йокысыннан арынып килгән халык рухи мирасын барларга тотына. Бүген тормыштан ризасызлык белдерүчеләр Казан Кирмәненең ул чактагы хәлен хәтерлиме икән? Шәһәр үзәгендә чүп өемнәре ятканны беләме? Әллә бүгенге хозурлык үзеннән-үзе килеп чыккан, дип уйлыймы?

Төзелеш мәйданын әзерләү, нәтиҗәдә, 1996 елда башланды. Бу изге эшнең башында Татарстанның беренче Президенты, хәзерге вакытта Республика җитәкчесенең киңәшчесе, «Яңарыш» фонды рәисе Минтимер Шәрип улы Шәймиев торды. Бүген рухи мирасны барлау дәвам итә. Кол Шәриф мәчетен салу бу эшләр чылбырының беренче буыны булды.

Ни кызганыч, 1552 елда җимерелгән гыйбадәт йортының рәсемнәре сакланмаган. Аерым язма чыганаклардагы мәгълүматларга таянып, тарихчылар аны сигез манаралы мәчет дип тасвирлый. Яңа мәчет проектларын тәкъдим итүчеләргә дә шундый таләп куела. Нәтиҗәдә, 2005 елда Казанның үзәгендә һәрберсе 58 метрлы дүрт төп һәм ике өстәмә манаралы, фирүзә гөмбәзле мәчет калкып чыга. Шулай да манаралар саны барыбер сигезгә тула: бәйтулла ишеге өстендә ярымайлы ике кечкенә багана урын алган.

Проект авторларының берсе, архитектор Сергей Шәкүров Кол Шәриф мәчете бинасының гаҗәеп катлаулы инженерлык конструкциясен тәшкил итүен әйтә. Мәчетнең эчендә баганалар юк. «Бертөрле дәһшәт, куркыту» уятуның бер сере дә шундадыр бәлки: намаз бүлмәсендә үзеңнең галәмнәр дәрәҗәсендә никадәр кечкенә һәм зәгыйфь икәнлегеңне аңлыйсың...

Мәчет проектын әзерләгән төркем җитәкчесе, архитектор Айвар Саттаров бер әңгәмәсендә бу тарихи вакыйга турында болай дип сөйли: «1996 елда Кол Шәриф мәчете проектына конкурс игълан ителгән иде.

ДӘВАМЫ 7 НЧЕ БИТТӘ

### Остаз һәм дус сайлау турында



БИТ 3

### Ихсан - диннең нигезе



БИТ 4

### Татар теле һәм яшьләр



БИТ 5

## Россиядә мөселманнарның яңа үзәкләшкән оешмасы барлыкка килде

Яңа үзәкләшкән дини оешма – «Россия мөселманнарының рухи җыены» («Духовное собрание мусульман России») теркәлү узды.

Мөфтият учредительләре: Мәскәү һәм Үзәк төбәк мөселманнары диния нәзарәте, Чуаш Республикасы мөселманнары диния нәзарәте һәм Себер мөселманнары диния нәзарәте.

Рәис итеп Әлбир Крганов сайланылды.

## Балаларга – хәләл ризык

Казан шәһәренең азык-төлек һәм җәмәгать туклануы департаменты Татарстан мөселманнары диния нәзарәтенең «Хәләл» стандартлар комитеты соравы буенча хәләл менюлы мәктәпкәчә яшьтәге һәм урта белем бирү учреждениеләре исемлеген игълан итте. Балаларны шәригать таләпләренә туры килгән ризык белән тукландыручы мәктәпләр һәм балалар бакчалары исемлеген Республика мөфтияте сайтында (dumrt.ru) табып була.

## Татарстан Воркута мөселманнарына ярымай бүләк итте

Татарстан Кол Шәриф мәчетенең артык калган ике метрлы, алтын йөгертелгән ярымаен Воркута мөселманнарына бүләк итеп җибәргән. Биредә яңа гыйбадәт йортын 2018 елда салып бетерергә ниятлиләр. Төзелешкә башка төбәкләр дә ярдәм итә. Әйтик, Дагыстан мөфтие биргән фатирны саткан акчага узган җәй цоколь каты ясалган. Бер ук вакытта 400ләп кеше намаз укый алачак фирүзә гөмбәзле, ак диварлы мәчет бинасында китапханә һәм ислам тарихы музее да булачак.

## «Хузур» нәшрияты «Исламская линия доверия» китабын чыгарды

2014 елның 1 октябреннән Islam-Today сайтында «Исламская линия доверия» дип аталган яңа проект башланып киткән иде. Биредә укучылар күңелләрен борчып торган сорауларын психологка бирә ала. Проект тормышка ашырыла башлаганнан бирле авторларга Россия һәм чит илләрдән меңләгән сорау килгән. Шуларның иң кызыклыларын һәм популярларын туплап, җавапларын барлап, «Хузур» нәшрият йорты «Исламская линия доверия» дип аталган китап итеп чыгарды.

## «Хөсәения» мәдрәсәсенә 125 ел

Россиянең иң борынгы мөселман уку йортларының берсе – Оренбурдагы «Хөсәения» мәдрәсәсенә нигез салынуга 125 ел тулды. Шул уңайдан һәм мәдрәсәнең яңадан эшли башлавына 25 ел тулуга туры китереп, Оренбурда «Ислам мәгарифе: бүгенге вазгыять һәм үсеш мөмкинлекләре» дип аталган халыкара фәнни-гамәли конференция оештырылды.

Исегезгә төшерәбез, «Хөсәения» мәдрәсәсе 1891 елда бертуган сәүдәгәрләр һәм хәйриячеләр Хөсәеновлар тырышлыгы белән ачыла. Биредә Ризаетдин Фәхретдин, Сәгыйть Рәмиев, Сәгыйть Сүнчәләй, Шәриф Камал, Фатыйх Кәрими кебек шәхесләр укыта.

# «Әс-Сәләм» газетасы хәзер татар телендә дә

Бисмилләәһир-Рахмаанир-Рахиим!

Аллаh Раббыбызга шөкер, дин тоту, йолаларны башкару фырсаты биргән иркен илдә һәм иректе чорда яшибез. Алай гына да түгел, үз динебез турында сөйли, башкаларны да вәгазьли алабыз. Ватаныбыз – күпмилләтле туган җиребез – биредә яшәүче һәр халыкка үз телендә сөйләшү, үз динен тоту мөмкинлеге бирә. Шушы җирлектә гомер кичерүче бихисап халыкларның, төрле диннәрнең, гореф-гадәтләренең, мәдәниятләрнең үзара дус-тату яшәве дәүләтнең бүгенге тынычлыгын тәэмин итә һәм киләчәктә яңа үрләр яулау өчен нык нигез булдыра. Россиядә яшәүче халыкларга хөрмәт - илне тотрыклы итә. Халыкны хөрмәт итүнең иң зур юлы – аның телен хөрмәт итү. «Әс-Сәләм» газетасы бу юнәлештә бик тә кирәкле эш башкара. Дин турында төрле телдә төгәл мәгълүмат җиткерә. Шулар исәбенә татар теленең дә кушылуы, җир йөзендә сибелеп яшәгән татарлар өчен, ил өчен, басманың үзе өчен дә бик кирәк. Бүген дәгъват кылу аеруча әһәмияткә ия. Бүгенге дәгъват – дингә чакыру гына түгел, Аллаһы Тәгалә иң камил рәвештә яраткан ислам динебезне ныгыту да. Динне пычратып күрсәтергә тырышучылар, яла ягучылар Пәйгамбәребез Мөхәммәд (сәлаллаһ галәйһи вәсәлләм) заманында да булган, бүген дә бар. Әмма алтын, пычрак белән буялмас. Пакъ агым су, алтынны ничек чистартса, шуның кебек хак мәгълүмат та халыкка диннең асылын ача. Бу бик катлаулы, әмма гаҗәеп дәрәҗәдә бәрәкәтле юл. Әлеге эштә мөмкин булган һәр алымнан файдаланырга кирәк. Бүген интернет заманы дип, басма мәгълүмат чараларыннан баш тарту дөрес булмас. Интернетта да, телевидениедә дә, радиода да һәм газета-журналларда да Ислам диненең тынычлык дине булуы турында сөйләү, күрсәтү, язу кирәк.



Бу башлангыч дәвамлы булса иде. Дәгъват, динебез Исламны үстерү юлында Аллаһы Тәгалә ярдәмче булсын.

**Әлбир хәзрәт Крганов,**
**Россия мөселманнарының дини җәмгыяте (мәҗлесе) рәисе, мөфти, Россия Федерациясе Иҗтимагый пулатының милләтара һәм конфессиара мөнәсәбәтләрне камилләштерү комиссиясе әгъзасы**

# Ислам яңарышы юлында

Бисмилләһи-Рахмани-Рахим!

Әссаләму галәйкум вә рәхмәтуллаһи вә бәракәтуһу! Мөхтәрәм газетаның укучылары!

Ниһаять, «Әс-Сәләм» мөселман газетасы татарча да дөнья күрде. Бүгенге глобальләшү чорында үз халкыңның телен, йола, гореф-гадәтләрен, милли һәм дини традицияләрен саклап калуның әһәмиятен әйтеп тә торасы юк. Бигрәк тә туган тел проблемасы бүген мөселман яшьләре арасында актуаль проблемага әйләнде. Яшьләребездә туган телгә, халкыбыз тарихына мәхәббәт сүрелә бара кебек. Дини тәгълиматны тирәнтен өйрәнү белән генә чикләнеп калу омтылышы да ят түгел аларга. Югыйсә бит нәкъ менә туган тел, халкыбыз тарихында Ислам диненең күп гасырлар дәвамында тоткан урынын тирәнтен аңлау, бүгенге көндә җәмгыятьтә барган Ислам яңарышын дөрес юлдан җибәрү өчен бик мөһим. Ислам диненең асылына күп гасырлык традицияләрне тирәнтен аңлау аша төшенергә омтылу бүген шулай ук бик мөһим проблемаларның берсе булып тора. Татар телле «Әс-Сәләм» мөселман газетасы, минә бу мәсьәләләрне тирәнтен аңлау һәм хәл итү юлларын эзләү өчен, һичшиксез, яңа мәйданчык булачагына ышанып калам.



**Россия Ислам институты ректоры Рәфикъ Мөхәммәтшин**

# Мөфти Чаллыда яңа мәчет ачылышында катнашты

Бүген Чаллының Мәләкәс аръягы бистәсе 27 нче микрорайонында төзелгән Утыз Имәни исемендәге мәчет ачылды. Әлеге күркәм чарада Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин, Чаллы шәһәре имам-мөхтәсибе Әлфәс хәзрәт Гайфуллин һәм башка дин әһелләре, кунаклар катнашты.



Мәчет 2014 елда төзелә башлаган. Мәхәлләне оештыручыларның күпчелеге Чирмешән районының Утыз Имәни авылыннан булганга, аңа ошбу авылдан чыккан дин галимебез, шагыйрь Габдрәхим Утыз-Имәни исемен биргәннәр.

Мәчет мөселманнарга хезмәт күрсәтәчәк тулы бер комплекс итеп күзалланган. Ир-атлар һәм хатын-кызлар өчен намаз бүлмәләре, дәресләр алып барырга классләр, имам бүлмәсе бар.

Татарстан мөфтие мәчетне ачканда җыелган халыкка мөрәҗәгать итеп: «Бу мәчет танылган татар фикер иясе, дин әһеле Утыз Имәни исемен йөртә. Утыз Имәни яңа заманда иҗтимагый-мәдәни һәм дини гореф-гадәтләрне аңлауга зур өлеш керткән шәхес. Әлеге мәчет тә җирле халык өчен намаз укып дога кыла торган урын һәм рухи-мәгърифәтчелек үзәге булсын», - диде.

Чыгышлардан соң мөфти рәсми вәкилләр, дин әһелләре белән бергә яңа мәчетне карады, мәхәллә халкы белән аралашты, сорауларга җавап бирде. Чара өйлә намазын уку белән тәмамланды.

Утыз Имәни 100дән артык хезмәт язган шәхес. Аларның күпчелеге гарәп һәм фарсы телләрендә. Үз заманында дин әһеле язганнар халык арасында кульязма рәвештә таралган.

# Сбербанк ислам банкингы хезмәтләрен сыный

Сбербанк Татарстанда ислам банкингы хезмәтләрен күрсәтә башларга ниятли. Бу хакта кредит оешмасы вәкилләренә сылтама белән Rambler News Service хәбәр итә. Шулай ук проект Башкортстан территориясендә дә тормышка ашырылырга мөмкин. Хәзерге вакытта банк шәригатьчә финанслауны гамәлгә кертергә әзерләнә.

# Милләтләр эшләре буенча агентлык диннәр турында белешмәлек чыгарды

Россиянең милләтләр эшләре буенча федераль агентлыгы дәүләт һәм дин оешмаларының үзара бәйләнешлары мәсьәләләренә багышланган кулланма чыгарды. Дәүләт структурасы матбугат хезмәте хәбәр итүенчә, әлеге документ, нигездә, башкарма хөкүмәт һәм хокук саклау органнарына атап төзелгән.

Россия эчке эшләр министрлыгы һәм юстиция министрлыгы белән берлектә булдырылган кулланмада ил халыкларының төп диннәре һәм яңа агымнар турында язылган. Шулай ук үзәкләшкән дини оешмалар белән элемтәгә керү өчен мәгълүмат бирелгән.

## «ДАИШ – XXI гасыр чумасы»

Ханты-Манси автономияле өлкәсендә узган «Себер шартларында яшьләрне социальләштерүдә ислам традицияләре һәм кыйммәтләренең роле һәм әһәмияте» төбәкара форумы кысаларында «ДАИШ – XXI гасыр чумасы» дип аталган ток-шоу оештырылды. Лянтор шәһәрендә үткәрелгән чарада Мәскәү, Үзәк төбәк һәм Чуаш Республикасы мөфтие, Россия Федерациясе иҗтимагый пулатының милләтара һәм конфессиара мөнәсәбәтләрне камилләштерү комиссиясе әгъзасы Әлбир хәзрәт Крганов та катнашты.

## Россия ислам институтында Ачык ишекләр көне



17 декабрьдә Россия ислам институты дини югары уку йортына укырга керү тәртипләре белән таныштыру максатыннан «Ачык ишекләр көне»н уздыра. Чара кысаларында югары уку йорты ректоры Рәфыйк Мөхәммәтшин, кафедра җитәкчеләре, мөгаллимнәр белән очрашулар планлаштырыла, 2017 елда институтка керү тәртипләре аңлатыла.

РИИ адресы: Казан шәһәре, Газ урамы, 19. Белешмәләр өчен телефон: (843) 251-01-55

# Рухи остаз мәктәбе

**Бу елның 3 ноябрендә Татарстан Диния нәзарәтендә узган VII нче Саматов укуларыннан.**

Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең Россия ислам институты һәм Казан ислам университеты белән берлектә башкарган уңышлы проектлары арасында быел җиденче тапкыр уздырылган Саматов укуларын да күрсәтергә мөмкин. Мәгълүм дин әһелләре, галимнәр, мөгаллим-остазлар һәм Казаныбыздагы өч дини уку йортында укучы шәкертләр катнашкан әлеге фәнни-гамәли конференцияне хөрмәтле хәзрәтебез Габделхак Саматов мисалы аша рухи мирасыбызны барлауда чираттагы җитди чара, ачык дәрес дип карарга кирәк. Дин кысылган атеистик совет чорында да хәзрәтләребезнең ничекләр итеп халык күңеленә ачкыч табулары, үзләре яшәгән җәмгыятьтә шул система белән каршылыкка кермичә халыкка ислам нигезләрен җиткерү, әдәп-әхлак тәрбиясе ирештерү юсыллары, килешегез, бүген дә актуаль. Ә бу яктан караганда Габделхак хәзрәт Саматовның эшләү-яшәү рәвеше бик күпләребезгә хикмәтле мисал, кыйммәтле чыганак булып тора. Һәм Саматов укуларына Татарстаныбыздан гына түгел, Идел-Урал регионыннан дин-мөбиндә исемнәре яхшы таныш кунаклар чакырылуы – сөйләшүнең быел да үткән белән бүгенгене бәйләүдә тагын бер адым булуын дәлилли.

Татарстан Республикасы мөселманнарының Диния нәзарәте рәисе, мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин да әлеге чараның әһәмиятен югары бәяли.

-Габделхак хәзрәт Саматов динебезне саклап калуда гаять зур тырышлык куйган остазыбыз. Шәригать хөкемнәрен халык аңларлык гади итеп җиткерүе белән милләттәшләребез күңеленә уелган хәзрәт. Кулга тотып укырлык бернинди дәреслек, китап булмаган совет заманында ук уку-укыту өчен дәреслекләр язган фидакарь, тәвәккәл һәм ихлас хәзрәт. Бүген аның эшчәнлегенә кабат мөрәҗәгать итеп, яшь алмашка шушы традицион ислам кыйммәтләрен аңлатырга омтылабыз, дәвамчыларын тәрбияләүне максат итәбез,- диде тантананы ачып мөфти хәзрәт. – Рухи мирасыбызны саклауга күп тырышлык куйган, дин-исламны алып баруга өлеш кертүчеләр арасыннан иң лаеклыларга ел да Татарстан Диния нәзарәте шушы чара кысаларында «Рухи мирас» бүләге тапшыра. Быел әлеге олы бүләккә Татарстан Дәүләт Советының мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе, депутат Рәзил Вәлиевне лаек дип таптык дип, Рәзил Исмәгыйль улын чакыруга, әлеге бүләк тапшырылган, күкрәк билгесе тагылган вакытта, конференциягә җыелучылар тәкъбир әйтеп тордылар.

-Шушы ышанычыгыз һәм бәягез өчен зур рәхмәт,- диде җавап сүзендә Рәзил әфәнде. – Бу бүләккә лаек булуыма башта гаҗәпләндем. Бу миңа узган гомеремә, нәселемә, башкарган эшләремә борылып карарга, барларга сәбәп булды. Беренче гонорарымны алгач, авылыма кайтып, мәчет манарасына айны куйдырган идем. Дәүләт советында мин рәислек иткән милли мәсьәләләр комитетында дини мәсьәләләр дә керә. Корбан гаете көнен ял көне итүгә ирештек. Дәүләт советында иң беренчеләрдән вөҗдан ирекe һәм дини оешмалар турында канун кабул иттек. Аны әзерләүдә һәм кабул итүдә күп тырыштым.

Бүгенгедәй җитди чараларның, форумутырышларның алыштыргысыз алып баручысы, хәзергәчә әйтсәк модераторы – РИИ һәм КИУ ректоры, мөфти урынбасары, Россия Федерациясенең ислам мәгарифе советы председателе, сәясәт фәннәре докторы, профессор Рәфыйк Мөхәммәтшин Габделхак хәзрәт Саматовның ислам яңарышындагы милли факторны тирәнтен аңлап эш иткән шәхес булуын дәлилләүче мисалларга туктала – туктала, кунакларга сүз бирде.

Ханты-Манси автоном өлкәсе мөфтие, хәзрәтнең улы Таһир хәзрәт Саматов чыгышын әлеге укуларны оештыручы һәм эзлекле төстә дәвам иттерүче, динебездә якты эз калдырган хөрмәтле затларыбыз мирасын барлап, шуны китап итеп бастыручы Татарстан Диния нәзарәтенә рәхмәт әйтүдән башлады.

-Әтинең бөтен яшәү, эшләү рәвеше динебезгә, халкыбызга хезмәт итү мисалы, дәгъват дәресе булды. Әтием остаз булды миңа да, тирә-якта да. Мин бай мирасыбызны белеп үссен дип тырышты.

Ә динне таратыр өчен Мәрҗани мәчетенә гади слесарь булып эшкә керде. Слесарьның эш урыны – идән астында. Әти әнә шунда яшертен мөгаллимлек итте, шул шартларда да укыту җаен тапты. Еллар үткәч, әти эшләгән шартларны күздән кичереп, шуңа гаҗәпләнәм: Мәрҗани мәчетендә ул елларда олпат затларыбыз - Әхмәтзәки хәзрәт, Габделхәбир хәзрәтләр имамлык иткән, Зәкәрия хәзрәт, Касыйм абыйлар эшләгән.



Рәзил Вәлиевка, мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин тарафыннан «Рухи мирас» бүләген тапшыру

аның гаиләдә дә, башкалар белән дә нинди мөнәсәбәттә булуын әчтән күреп үстем. Машинасында китабын, намазлыгын, комганын калдырмады. Кечкенә чактан ук, әле укыргаязарга өйрәнгәнче үк Һәфтияк шәрифне яттан белә идек инде. Милли тәрбиягә, гореф-гадәтләргә сак мөнәсәбәте, хөрмәте шушы мисалда ачык чагыла. Якында гына мәктәп булуга карамастан, без дүртебез дә Казанның икенче почмагындагы татар мәктәбенә ике трамвай белән йөреп укыдык. Баруга гына да бер сәгать китә иде. Татар мәктәбе бетмәсен дип тырышты. Балаларым ана телендә тарихын, тамырларын, Ни хикмәт, менә алар бербересенә саф бирганнәр, тату эшләгәннәр. Ихласлык булганда ике тәкә башы гына түгел, әллә ничә тәкә башы сыйган.

Әти гыйлемен көне-төне таратты, буш вакыты булмады да. Ислам дине – ихласлык, күркәмлек, сабырлык, тәкъвалык дине. Бернинди ачу, көнләшү, мәкер, усаллык кебек сыйфатларга урын булырга тиеш түгел. Әтиебезнең яшәү рәвеше нәкъ шундый булды. Әти бөтен кешене кичерә, гафу итә белде, безгә бик матур эстафета калдырды. Аллаһы Тәгалә милләтебезгә абруй-дәрәҗәгә ирешергә насыйп итсен!- диде Таһир хәзрәт.

Самара өлкәсе мөфтие Талиб хәзрәт Яруллин совет чоры муллаларының шул чор шәхесләре булуларын, халыктан аерылмыйча, динебезне дөрес итеп алып баруда зур эз калдыруларын Габделхак хәзрәт мисалларында сөйләде.

Динебездәге тәртипне саклап, халкыбыз традицияләрен дәвам итүче Татарстанның баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыевның, мөфтиятнең дәгъват бүлеге җитәкчесе, тарих фәннәре кандидаты Нияз хәзрәт Сабировның, Бөтендөнья Татар конгрессының бүлек җитәкчесе Фәрит Уразаевның, Сызрань шәһәре имам-мөхтәсибе Илгизәр хәзрәт Сәгъдиевның һәм яшь галимнәрнең һәркайсының чыгышы, фәнни хезмәтләре совет чоры имамнары, Габделхак хәзрәт Саматов эшчәнлегенә карата да олы хөрмәт белән сугарылган иде. Тирән тамырлы дини мирасыбыздан өзелмичә, динне, милләтне аермыйча, җәмгыяви җаваплылыкны саклауга киләчәктә дә игътибар бирү мөһимлеге кат-кат яңгырады. 60 еллык динсезлек, өч буынның динсез үсүе дәверендә муллалык иткән, шушы бушлыкны тутырган Габделхак Саматов үрнәге һәм дә аның дин ирегe килгән 90 нчы еллардагы күпкырлы эшчәнлеге дә өйрәнүгә, дәвам иттерелүгә бик тә лаек.

(2010 елны Таһир хәзрәт Саматов белән берлектә Габделхак хәзрәтнең тууына 80 ел тулуга багышлап «Халык күңелендәге Габделхак хәзрәт» дигән тарихи-публицистик басма әзерләгән идек. Әлеге вакыйгадан соң күп сулар акты. 3 ноябрьдә узган чираттагы фәнни-гамәли конференциядә күрешкәч, «Әти хакында хәтирә-истәлекләр туплавыбыз, замандашларыннан сөйләтүебез дә хәзер кыйммәтле чыганак. Халык яратты китапны, эзләп табып укыйлар,» - дип Таһир хәзрәт миңа әлеге зур эшне башкарып чыгучы мөхәррир буларак гаиләләре исеменнән рәхмәтен җиткерде).

**ВӘСИЛӘ РӘХИМОВА**

**КАЗАН ШӘҺӘРЕ**

ГЫЙЛЕМ ОРЛЫКЛАРЫ

# Остаз һәм дус сайлау турында

**Җәгъфәр әл-Садыйк Суфьян әл-Сәүригә әйтте: «Башкарасы эшләрең турында Аллаһы Тәгаләдән куркучылар (галимнәр) белән киңәш», – диде.**

Гыйлем алу – эшләрнең иң югарысы һәм иң авыры, шуңа күрә белем эстәгәндә дә киңәшү кирәк.

Сәмәрканд галиме сүзен дәвам иттерә: «Бохарага баргач, остаз сайларга ашыкма. Ике ай көт, барысын да уйлап бетер һәм шуннан соң үзеңә остаз сайла. Бәлки син бер галимгә барырсың да аннан дәресләр ала башларсың, аның укытуы сиңа ошамас һәм син, аны калдырып, икенче остазга китәрсең – нәтиҗәдә, белем эстәвеңнең бәрәкәте булмас. Шуңа күрә, соңыннан аннан баш тартмас өчен, остаз сайлаганчы ике ай уйла, киңәшләш. Укуың бәрәкәтле булсын һәм син өйрәнгән



гыйлемнәреңнән бик күп файда алсын өчен. Шул очракта син остазың янында калачаксың».

Бел, түземлелек һәм үҗәтлек теләсә кайсы эшнең беренчел нигезе булып тора.

Хәбәр ителә ки, батырлык – ул бер сәгать дәвамында түзеп тору. Шәкерткә остазга (аны ташлап китмәскә), китапка (аны тәмамламыйча калдырмаска), фәнгә (берсен камил рәвештә өйрәнеп бетермичә башкасына күчмәскә), шәһәргә (җитди сәбәпсез бер урыннан икенче урынга күченеп йөрмәскә) карата үҗәтлек һәм түземлелек күрсәтү кирәк.

Чөнки югарыда аталган күренешләр аның игътибарын җәелдерә, йөрәгеняулый, вакытны әрәм итүгә китерә һәм остазын үпкәләтә.

Кешенең нәфесе теләгән нәрсәләргә карата түземлелек күрсәтү таләп ителә.

Сынауларга һәм бәхетсезлекләргә карата түзем булу кирәк. «Максатларның хәзинәсе авырлыклар артына яшерелгән», диелә.

Дус сайлауга килгәндә, тырышракны, Аллаһы Тәгаләдән куркучанракны һәм күркәм холыклыны сайлау, ялкау, эшсез, күп сүз сөйләүче, нәфесе артыннан иярүчедән ераграк тору кирәк.

Аллаһ Илчесе әйткән: «Һәр бала мөселман булып туа, ә әти-әнисе аннан яһүди, насара яисә хәтта утка табынучы ясый».

Фарсы телендә «Хикмәт» китабында болай дип язылган: «Начар дус агулы еланнан начаррак. Аллаһ белән ант итәм, хактыр ки, начар дус сине һичшиксез Җәһәннәмгә илтәчәк, ә яхшысы – Җәннәткә алып барачак».

**Борһан әл-Ислам әл-Зәрнүҗинең «Тәгълим әл-мөтәгаллим» («Белем эстәүчеләргә нәсыйхәт») китабыннан**

ГАЗЕТА БИТЛӘРЕНДӘ КОРЪӘНИ КӘРИМДӘГЕ АЯТЬ-СҮРӘЛӘР УРЫН АЛГАНЛЫКТАН, БАСМАГА ИГЪТИБАРЛЫ БУЛУЫГЫЗ СОРАЛА!

# «Әбүгалисина мәгарәсе» ндә

**Мәдрәсә шәкертләре өчен уку ярдәмлеге эзләп йөри торгач, бер китап кибетенә юлыктым. Хәйран калып карап торам: дивар буйлап идәннән түшәмгә кадәр тезелеп киткән шүрлекләрдә, өстәл өсләрендә, хәтта идәндәге тартмаларда да китап... Әбүгалисина мәгарәсе диярсең. Бу «Иман» нәшриятының Апанай мәчетендә урнашкан китап кибете булып чыкты. Татарстанда әлеге нәшриятта басылып чыккан китапларны укымаган татар кешесе юктыр, дип беләм.**

Билгеле булганча, егерменче гасырның 80-90 нчы елларында дингә ирек бирелгәч, дәүләтнең ярдәме белән мәчетләр ачыла, иске мәдрәсәләр торгызыла башлады. Әмма халыкның әлифнең таяк икәнен белерлек гыйлеме, тотып укырлык китабы юк иде әле. Шул вакытта милләтпәрвәр шәхес Вәлиулла хәзрәт Якупов дингә булган рухи ихтыяҗны күреп алды; тарихыбыз, динебез, гореф-гадәтләребез турындагы мәгълүматны милләттәшләребезгә тизрәк җиткерергә кирәклекне аңлады. 1990 елның 29 ноябрендә ул «Иман» яшьләр үзәген оештырды. Шунда тарихчыларны, дин әһелләрен, яшьләрне җыя иде. Һәм алар динебезне, мирасыбызны халыкка җиткерү өчен китаплар бастыра, газеталар чыгара башларга кирәк, дигән карарга килә. Шулай итеп, 1992 елның августында татар телендә «Иман» газетасы чыга башлый. Соңрак рус телендә «Вера» дигән газета, татар телендә «Иман нуры» дигән журнал, татарча мөселман календаре, 1998 елда «Мусульманский мир» журналы дөнья күрә.

Вәлиулла хәзрәт хәнәфи мәзһәбе мирасын да халыкка җиткерергә тырыша. «Иман» нәшрияты Татарстан мөфтияте, Казан мөхтәсибәте, төрле уку йортлары һәм дини оешмалар белән һәрчак тыгыз элемтәдә тора. 1992 елның 6 ноябрендә Апанай мәчете мәхәлләсе оешып, шушы мәчет каршында «Иман» нәшрияты догалар, хөтбәләр, намаз шартлары, ураза тәртипләре кебек һәр мөселманга кирәкле китапчыклар бастыра башлый. 1993 елда «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе ачылганнан соң, шәкертләр өчен беренче дәреслекләр дә нәкъ менә «Иман» нәшриятында әзерләнә (әле хәзер дә кайбер фәннәр шушы нәшриятта бастырылган китаплар буенча укытыла). Шулай ук нәшриятның Мәсгут Гайнетдин, Хатип Миңнегулов, Дамир Исхаков, Рәфыйк Мөхәммәтшин һәм башка мәшһүр татар галимнәре белән хезмәттәшлеге нәтиҗәсендә милләттәшләребезгә бик тә кирәкле тарихи мәгълүмат җиткерелә. Революциягә кадәр иске татар телендә язылган китапларны хәзерге татар теленә күчереп бастыру, бай мирасыбызны халкыбызга кайтару исә бүгенге көндә дә дәвам итә.

Нәшриятның хәзерге директоры, Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте дәгъвәт бүлеге җитәкчесе, Апанай мәчете имам-хатыйбы, тарих фәннәре кандидаты Нияз хәзрәт Сабиров үзен Вәлиулла хәзрәтнең шәкерте дип саный.

- Мин Вәлиулла хәзрәт белән 90 нчы еллар уртасында таныштым. Ул чакта мәктәп укучысы, мәчеткә йөреп, дини белем ала идем. Вәлиулла хәзрәт уздырган чараларда катнаштым. Ул җитәкләгән нәшриятта хезмәт иттем, «Иман» һәм «Вера» өчен мәкаләләр яздым, тәрҗемә иттем. Вәлиулла хәзрәт миңа бик файдалы киңәшләрен бирде, инде менә аның эшен дәвам итәргә насыйп булды, - дип сөйли Нияз хәзрәт.


**Нияз хәзрәт Сабиров**

– Нәшриятның бүгенге көндәге эшчәнлегенә тукталсак, соңгы ике елда 50 дән артык китап бастырдык. Тәвәккәлләп, ислам дөньясында шактый мәшһүр дин галимнәре хезмәтләренә алындык. Әбү Габдулла Мөхәммәд бин Сәламә әл-Кудагыйның «Дәкаик әл-әхбәр» («Һәр мөселман өчен кирәкле мөһим хәбәрләр») хезмәтен бастырдык. Аны гарәп теленнән татарчага Галиәсгар Камал тәрҗемә иткән булган.

Танылган ислам галиме, җәмәгать эшлеклесе, Мисыр мөфтие Мөхәммәт Габдонын 30 нчы җүз тәфсирен бастырдык. Аның кайбер фәтвалары күпчелек сөнни галимнәрнең фәтваларына ихтилафлы булса да, танылган татар галиме Шәйхелислам әл-Хәмиди Мөхәммәд Габдоның шушы тәфсиренең әһәмиятен күреп, татар теленә тәрҗемә иткән. Теле авыр, ләкин бу безнең мирас. Шулай ук «Әмәли» китабын бастырдык. Бу китап әһле сөннәт һәм җәмәгать гакыйдәсе буенча бик әһәмиятле хезмәт булып тора. Әлеге әсәр шигъри юллар белән язылган һәм безне Имам Әбү Мансур Мәтуриди мәзһәбе гакыйдәсе белән таныштыра.

«Әмәли» китабының авторы – Фирганә өлкәсе Ош шәһәрендә туган мәшһүр галим Сираҗеддин Габделхәсән Гали бин Госман әл-Оши (һиҗри ел исәбе буенча 569 елда үлгән). Кыска гына вакыт эчендә хәнәфиләр арасында бу әсәр мәшһүрлек ала һәм хәзерге көндә дә ул Хәнәфи мәзһәбе мәдрәсәләрендә яттан өйрәнелә.

Кадими булган татар мәдрәсәләрендә бу китап уку-укыту программасына мәҗбүри кертелгән һәм танылган галим Шәйхелислам әл-Хәмиди тарафыннан татар теленә дә тәрҗемә ителгән. Күптән түгел «Нәвадир» (Хикмәтле хикәяләр җыентыгы) тәрҗемәсен бастырдык. Әлеге хикәяләр урта гасыр гарәп әдәбиятының бер өлеше булып тора. Ул хикәяләрдә пәйгамбәрләр, изгеләр, олуг шәхесләр белән бәйле булган төрле вакыйгалар тасвирлана, үгет-нәсыйхәтләр бирелә. Кайбер хикәяләр бүгенге көндә дә үз әһәмиятен югалтмаган. Казанда берничә мәртәбә басылган. Мәшһүр татар дин әһелләре турында китаплар әзерләүне дәвам итәбез.

Гарифулла ишан Гайнуллин, Әхмәтзәки хәзрәт Сафиуллин турында китаплар чыгардык, Габделхәбир хәзрәт Яруллин турында Җәгъфәр Мөбарәк язган китап басыла.

- Бу кадәр күләмле эшне алып бару өчен әзерлекле белгечләр булу да кирәк...

- Безгә иң зур ярдәм күрсәткән шәхесләрнең берсе - Әхмәт хәзрәт Сабиров. Заманында ул Вәлиулла хәзрәтнең урынбасары, киңәшчесе иде. Хәзерге вакытта да «Иман» нәшриятында хезмәт итә. Нәшрият бүлеген тәҗрибәле белгеч - Радик Әдһәмов җитәкли. Без күбрәк галимнәр белән эш итәбез.

Аллаһка шөкер, китаплар басыла һәм үзегез дә күреп гаҗәпләндегез - безнең кибеттә беркайда да сатылмаган, беркемдә дә булмаган китаплар бар. Бу – зур хәзинә. Хәтта галимнәр, аспирантлар да фәнни хезмәтләрен язганда, кирәкле әдәбиятны эзләп, безгә киләләр.

**НӘҮБӘҺАР КӘБИРОВА**

**КАЗАН ШӘҺӘРЕ**

ТАРИХ БИТЛӘРЕННӘН

# «Мәрҗания́», Казандагы мәдрәсә

1770 елларда Казанның 1 нче мәхәллә мәчете каршында ачыла (к. Мәрҗани мәчете). 1870 еллардан шунда укыткан Ш.Мәрҗани исеме белән атала; аңа кадәр Ахун, Юныс мәдрәсәсе буларак билгеле. Беренче мөдәррисе А.Ибраһимов була (1793 тә вафат). Ибраһим бине Хуҗаш әл-Казани (1825 тә вафат) мәдрәсәне Идел-Урал төбәгендә иң танылган уку йортларының берсенә әверелдерә (фәлсәфә укытуның югары сыйфаты белән аерылып тора).

19 йөзнең 2 нче яртысында укыту дәрәҗәсе түбәнәя. Ш.Мәрҗани җитәкләгән 1850–89 елларда мәдрәсә эре мөселман уку йортына әверелә, анда, гадәти фәннәрдән тыш, математика, астрономия, тарих укытыла; якынча 140 шәкерт укый. Ш.Мәрҗани белән И.Юнысов арасындагы каршылык нәтиҗәсендә, 1860 еллар ахырыннан 1870 еллар ахырына кадәр 1 нче мәхәлләдә 2 мәдрәсә эшли; берсе белән Мәрҗани җитәкчелек итә, ул күпчелек бай шәһәр кешеләре акчасына тотыла; икенчесе рәсми рәвештә 1 нче мәхәллә мәдрәсәсе санала, И.Юнысов акчасына тотыла, ләкин аның карашлары мөселман җәмәгатьчелеге тарафыннан тәнкыйть ителгәнлектән, ябыла. 1889–1908 дә мәчетнең имам-хатибы Б.Баһаветдинов (Ш.Мәрҗанинең улы) мөдәррис була; аның авыруы сәбәпле, 1899 га кадәр чынлыкта мәдрәсә белән мөәзин Х.Ихсанов җитәкчелек итә һәм бу чорда мәдрәсә үз дәрәҗәсен югалта. 1899 да аны имам С.Абдуллин алыштыра; ул эшләгәндә яңа ысулга нигезләнеп укыту кертелә һәм аның сыйфаты яңадан югары дәрәҗәгә ирешә. 20 йөз башында якынча 100 шәкерт укый. 1918 дә мәдрәсә рәсми рәвештә ябыла, ләкин 1923 кә кадәр С.Абдуллин шәкертләрне укытуын дәвам итә. Мәдрәсәне тәмамлаучылар арасында Х.Фәезханов, Г.Фәезханов, Г.Гомәри, Ш.Рәмзи, Г.Апанаев, К.Тәрҗемани, Х.М.Ямашев, С.Х.Айдаров, С.Җ.Сәйдәшев бар.

1820 дән мәдрәсә Кабан күле буендагы үзенә аталган агач бинага урнаша. 1837 дә аның урынына Г.Юнысов акчасына Икенче Аркылы урамда (хәзерге Ф.Кәрим урамы) яртылаш таш бина төзелә. Ш.Мәрҗани һәм И.Юнысов каршылыгы вакытында алар һәркайсы үз мәдрәсәләре өчен бина төзиләр: И.Юнысов 1873 тә — элеккесе урынында, Ш.Мәрҗани 1871 дә — Беренче Аркылы урамда (хәзерге З.Солтан урамы). Мәдрәсәсе ябылгач, Юнысов ул бинаны мәхәлләгә кайтармый; 1887 дә варислары аны Казан шәһәре мөселманнары хәйрия җәмгыятенә тапшыралар. Ш.Мәрҗани төзеткән бина 1875 тә яна; 1881 дә яңадан төзетелә (архитектура истәлеге). 2003 тә биредә яңадан «М.» мәдрәсәсе ачыла. 2004 тә ул Казан ислам көллияте итеп үзгәртелә.

**Әдәбият:**

**Мәрҗани Ш. Мөстафадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. К., 1990. Т. 2;**

**Хайрутдинов Р.Р., Салихов Р.Р. Исторические мечети Казани. К., 2005.**

## ИХСАН - ДИННЕҢ НИГЕЗЕ

Көннәрнең берендә пәйгамбәребез Мөхәммәд (аңа Аллаһның рәхмәте булсын) үзенең сәхабәләре белән җыелып утырганда аның янына кеше сурәтендә Җәбраиль фәрештә килде һәм ул пәйгамбәребездән (аңа Аллаһның рәхмәте булсын) диннең өч нигезе: иман, ислам, ихсан хакында сорады.

Соңгысына җавап биргәндә пәйгамбәребез (аңа Аллаһның рәхмәте булсын) болай диде: «Ихсан ул – Аллаһка күргән кебек гыйбадәт кылу, әмма син Аны күрмәсәң дә, син кая гына булсаң да Ул сине күреп тора». (Сахих Мөслим)

Без моннан шундый нәтиҗә ясыйбыз, димәк, Ихсан ул безнең җаваплылыгыбызны кайгырта. Без Аллаһка гыйбадәтне шундый нык ихласлылык һәм курку белән башкарырга тиешбез, Раббыбыз безне кая гына булсак та күреп - белеп тора, безнең кальбебездә ниләр барын, безнең нәрсә ниятләгәнебезне белә. Димәк, безнең күңелебезгә берәр начар уй килсә, кеше күрми дигән уй астында гөнаһ кылырга беренче адымга барганда шул вакыт безнең ихсаныбыз Аллаһ сине кая гына булсаң да күреп тора бит дип кисәтергә тиеш.

Без үзебез генә булганда кайвакыт шундый начар эшләр эшлибез, андый начар эшне ят кешеләр барында хәтта акыл дәрәҗәсе җитлегеп бетмәгән сабый бала да эшләмәс. Кайвакыт безнең кальбебезне төрле начар уйлар биләп ала, әгәр ул начар уйларыбызны янәшәдәге танышларыбыз, туганнарыбыз, дусларыбыз белсә, безгә шул хәтле оят булыр иде, хәтта алар безне түбәнсетеп куып җибәрерләр иде.

Моннан шул килеп чыга, димәк ки без кешеләрдән түбән зәгыйф затлардан оялабыз, әмма барысын да күреп - белеп, ишетеп торган безнең эшләребездән, уйларыбыздан, ниятләребездән хәбәрдар булган Хикмәт вә Гыйлем иясе Раббыбыз Аллаһтан оялмыйбыз булып чыга. Табигый, кеше кешеләр барында шәригатьә тыелган гамәлләрдән үзен чикли. Кагыйдә буларак, хәтта балалар да ата-аналары янында, туганнары, укытучылары янында ярамаган эшләрне эшләмиләр, әмма ата-аналары күрмәгән вакытта ярамаган эшләрне кылуы бик ихтимал. Кайвакыт балалар ата-аналарын таң калдырырлык эшләр эшләп ташлыйлар, ата-аналары минем балам андый эшкә барыр дип гомерендә дә уйлап карамый, чөнки аларның балалары этиәни күрми дигән уй астында ярамаганны эшлиләр һәм бу көннәрнең берендә мәгълүм була. Андый начар эшләрдән balаңны саклау өчен кече яшьтән Аллаһ сине кайда гына булсаң да күреп тора дип ихсанны, ихласлылыкны тәрбияләп кенә ирешеп була.

Бер кыйссада бәян ителә: бер галимнең күп укучылары булган, әмма алар арасындагы бер шәкертне галим күбрәк хөрмәт иткән, ихтирамлы булган, шуңа күрә калган шәкертләр аннан көнләшә торган булганнар. Аларның ни өчен ул шәкертне күбрәк яратасың? – дигән сорауларына җавап бирер өчен һәрберсенә берешәр тавык алып берәү дә күрми торган җирдә суеп алып килүләрен сорый. Икенче көнне барча шәкертләр суйган тавыклар белән килә, мәгәр галимнең яраткан шәкерте генә тавыкны тере килеш алып килә бу калган шәкертләрне көлергә мәҗбүр итә. Шунда галим сорый: «Ни өчен соң син тавыкны тере килеш алып килдең?» Шәкерт: «Сез бит безгә ул тавыкны берәү дә күрми торган җирдә суерга куштыгыз, мин Аллаһ Тәгалә күрми торган бер генә генә җир дә таба алмадым», — дип җавап кайтара. Галим шәкертләргә: «Менә шуның өчен дә инде мин аны күбрәк яратам», — ди. Ул шәкерт бик тә Иманлы, Ихсанлы булган. Аллаһ Тәгаләдән чын курку белән курыккан, һәм начар гамәлләр кылудан сакланган. Менә шуңа да инде Ихсан безнең динебезнең төше, йөрәге. Фәкать Ихсан гына Иманны һәм Исламны бербөтен итә.

# Татар теле һәм яшьләр

Бүген җир шарында булган 7 меңгә якын телләрнең 95 проценты бу гасыр азагында юкка чыгуга дучар. Белгечләр раславынча, телләрнең югалу процессы аерым җәнлекләр һәм үсемлекләр юкка чыгуыннан да кызурак бара. Мәшһүр Америка тел белгече Кеннет Хейл җир шарында бер телнең юкка чыгуын Лувр музееның юкка чыгуына тиңли. Тел – ул гади аралашу чарасы гына түгел, ул шул тел белән кулланучы этник группаның мәдәнияте белән үрелеп бара, ул халыкның рухи эшчәнлеген чагылдыручы чара. Телдә халыкның рухы да, табигате дә һәм тормыш-көнкүреше дә ачык чагыла. Тел өйрәнү ул тарихчылар һәм археологлар ирешә алмаслык серләрне ача төшә, халыкның рухият тамырларын ачып сала... Телдә халыкның көнкүреш һәм рухи тормышы, үткәне, хәзергесе һәм киләчәге чагыла. Шуңа күрә җир шарында кечкенә генә бер халыкның да юкка чыгуы кайтарылмаслык мәдәни югалту фаҗигасенә тиң.

Телнең яшәеше, киләчәге буыннар дәвамчылыгы, яшьләр белән бәйле. Казанда гына ел саен төрле мәктәпләрдән, урта белем бирү йортларыннан 16 меңгә якын бала татар телен өйрәнеп чыга. Ләкин, шуңа карамастан, Казанда татар телендә сөйләшүчеләр әллә ни артмый. Татар яшьләренең күпчелеге туган телен белми, белергә омтылмый да. Араларында ана телендә сөйләшергә оялучылар да бар. Үзләре дә сизмәстән кардәшенә татар телендә эндәшергә кыймыйлар. Ә тел бит ул сөйләмдә кулланылыш тапкан очракта гына яшәргә сәләтле.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан "Татарстан Республикасы халыклары телләре турында"гы законга кабул ителгәнгә ике дистә ел узды,ул законга үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында законнар кабул ителде. Татар телен дәүләт теле буларак гамәлгә ашыру дәүләт Программасы бар. Ул программа республикабызга 50 миллион сумга төште. 2004 елда 9 елга дип кабул ителгән яңа программа 122 миллион сум бюджетны тәшкил итә.

Татар теле чын мәгънәсендә соңгы 10-15 ел эчендә дәүләт теле була алды микән?

Сан ягыннан карасак, татар теле үсешен чагылдыручы үзгәрешләр шактый. Бигрәк тә бу милли мәгариф эшендә чагыла.

Татар милли мәгарифе – ул татар телендә уку-укытудан тыш, милли тәрбия, милли мохит булдыру, милли тәгълимат тәрбияләү чарасы. Татарстан республикасы Россиядә бердәнбер милли мәгариф эшен башлап җибәрүче төбәк булып тора. Татарстанның милли мәгариф доктринасы «Мәгариф» ассоциациясе, Тарих институты галимнәре катнашында Мәгариф министрлыгы тарафыннан төзелде. Республикада милли мәгариф системасының структуралары булдырылды, татар мәктәп-гимназияләре ачылды, мәктәпләргә гомуми мәҗбүри татар телен укыту кертелде, эзлексез татар телендә белем бирү мәсьәләсенә игътибар юнәлтелә, һөнәри белем бирү, югары уку йортларында татар телендә белем алу мөмкинчелекләре карала. Милли телне урта һәм югары белем өлкәсенә кертү буенча Татарстан барлык башка Россия регионнарына караганда иң алда. Шулай ук республикабыз Россиядә милли азчылык телендә техник белем алу мөмкинчелеген тудырган бердәнбер регион. Милли традицияләргә нигезләнгән мәгариф системасын төзү тәҗрибәсе үзен аклап бара. Бүгенге көндә татар мәктәпләрендә укыган 37 мең бала арасында бер генә хокук бозучы, полициядә исәптә торучы юк. Милли мәктәп тәмамлаучыларның 79 проценты югары уку йортларына керә.




Тел язмышы – яшьләр кулында

Шулай ук шактый гына балалар бакчаларында татар төркемнәре ачылды, татар телендә матбугат чаралары күбәйде, китаплар, сүзлекләр елдан ел басылып торалар.

Әлбәттә, уңай якка булган үзгәрешләрне санап китәрлек. Ләкин, моңа карамастан, чын мәгънәсендә яхшы сыйфатлы икетеллек Татарстанда узган унбиш ел эчендә урнашмады. Бу парадоксаль күренешнең төп сәбәбен белгечләргә дә, киң җәмәгатьчелектәхөкүмәтебезнең татар теленә карата булган эзлексез, икеләнүчән сәясәтендә күрәләр. Соңгы вакытларда Татарстан хөкүмәте тарафыннан татар теле статусын ныгыту өчен бернинди диярлек ныклы чаралар күрелми, дигән фикер еш очрый. Шәһәр администрацияләре органнарында һәм муниципаль учреждениеләрдә, төрле сәнәгать предприятиеләрендә һәм оешмаларда, эш итү теле буларак, урыс теле генә кулланыла.

Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә дә укытучын, тәрбия бирүнең сыйфатын арттыру; шәһәр хуҗалыгы тармакларында Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә эшләүче кадрларны тартып китерү өчен матди стимуллаштыру системасын булдыру нияте белән ике дәүләт телен кулланучыларга 15 % өстәмә түләү каралган иде. Ләкин шул ук законга 2004 елның июль аенда өстәлгән бер генә җөмлә бу башлангычны юкка чыгарды.

Нәтиҗәдә финанс идарәсе күрсәтмәләре юк дип, Министрлар Кабинеты әлеге өстәмә түләүләрнең шартларын һәм тәртипләрен ачыклауда тоткарлык күрсәтә.

Мәгариф өлкәсенә килсәк, ТР мәгариф министры приказы буенча РОНОларда милли эшләр буенча урынбасарлар вазифаларын бетерделәр. Татар авылларында балалар саны җитми дип татар мәктәпләре ябыла. Казанда булган татар мәктәп-гимназияларына керсәк, тәнәфестә укучыларның да, укытучыларның да рус телендә сөйләшүләрен күрәбез. Балалар бакчаларына да килсәк, татар сүзе җисеменә караганда күбрәк исеменә генә туры килә. Балаларны милли татар киемнәренә киертеп, татарча җырлатып-биетеп, шигырь сөйләтеп бәйрәмнәр үткәрәләр. Депутатларыбыз, БТК җитәкчеләре, язучыларыбыз, зыялыларыбыз шундый очрашуларга барып кәефләре бик күтәренке булып калалар. Ләкин ул ялтыравыклы фантик эчке халәткә тулаем туры килә микән? Бу күз буяу кемгә кирәк соң? Үзүзебезне алдыйбыз бит.

Бүгенге көндә милли мәгариф алдында торган иң зур проблема - ул дәүләт телләрен куллануны регламентлаштыру норматив-хокуки нигез, квалификацион база булмавы. Мәктәптә укыту эшен җирле җитәкчеләр (муниципаль берәмлек, Башкарма Комитет, мәктәп Советы) хәл итә. Мәктәпне тәмамлаганда рус теле буенча имтихан бирелмәсә беркая укырга кереп булмый, ләкин татар теленә бу кагылмый, татар телен белү шулай ук мәҗбүри куелмаган. Мәктәпләрдә татар теле укыту теле буларак дәүләт тарафыннан якланмый. Татар мәктәпләрен милли кадрлар белән ныгыту ниятеннән 1997 елда Казан мэры карары буенча татар мәктәпләренә, татар балалар бакчаларына эшкә татар телен белмәүчеләрне алмаска дип игълан ителгән иде. Шул чара нәтиҗәсендә мәктәпләрдә, балалар бакчаларында татар телле укытучылар, җитәкчеләр саны утыздан алып илле процентка кадәр җиткән иде. Ләкин бүгенге көндә әлеге таләп шундый ук катгый рәвештә үтәлми. Укытучыларны эшкә алу тулаем мәктәп директоры карамагында. Татар мәктәпләрендә укытучылар татар телендә генә укытырга тиеш дигән положение, карар, яки башка берәр рәсми норматив таләп юк.

Дәүләт телләрен куллануны регламентлаштыру норматив-хокуки нигез, квалификацион база булмавы ул милли мәгариф алдында гына торган проблема түгел, бу башка өлкәләргә дә кагыла.

Тел гамәли яктан куллануда булсын өчен аңа ихтыяҗ булдырырга кирәк. Менә монда инде гаилә көче дә, хәтта җәмәгатьчелек көче дә җитми бугай. Һичшиксез, телебезнең киләчәген булдыру өчен Татарстан Хөкүмәте һәм шәһәр хакимияте татар телен яклау һәм үстерү өчен хәлиткеч чаралар күрергә тиеш!

Безнең төп проблемабыз - Татарстанда татар халкының үсеше турында программа әлегә төзелгәне юк. Башкортларда андый программа бар. Россиядә рус телен үстерү буенча программа бар. Рус халкының мәнфәгатьләрен яклау буенча махсус законнар кабул ителгән.

Татарстан Конституциясенең 14 маддәсе читтәге татарлар мәнфәгате искә алып кабул ителгән иде. Тик бу маддә гамәлгә керсә дә, безнең Конституциябез Татарстанда гына хокукый көчкә ия. Димәк, мондый программаның федераль хакимият белән килешеп бөтен Россия күләмендә тормышка ашырырга кирәк.

Безне иң борчыган мәсьәлә - Россия төбәкләрендә милли мәсьәлә бик тә берьяклы хәл ителә. Рәсәй этно-милли мәгариф концепциясе төзелү процессында да Мәскәү тарафыннан регионнар тәҗрибәсе читкә кагыла, Россиядә яшәүче милләтләр мәнфәгатьләре исәпкә алынмый. Безнең яктан да бу процесска Татарстан халкын катнаштыру, киң җәмәгатьчелекнең игътибарын җәлеп итү, гражданлык активлыгына өндәү тиешле дәрәҗәдә түгел. «Бербөтен Россия сәяси милләте» («Единая российская политическая нация») идеясе Россиядә яшәүче халыкларның мәдәни үзенчәлекләре арасындагы аерманы юкка чыгара. Милләт төзелешенең территориаль принципы шул милләтне булдыручы мәдәниятләр арасында чишелмәслек каршылык туа.

Россия күләмендә татар халкын үстерү, алга җибәрү буенча дәүләт программасы булдырылырга тиеш. Һәм монда инде Татарстаннан тыш төрле төбәкләрдә яшәүче татарлар үз фикерләрен, таләпләрен җирле идарә органнарына, федераль хөкүмәткә даими рәвештә җиткереп торырга тиешләр.

Яңа программада аерым бүлеге татар теленә карата пиар – уңай караш булдыруга юнәлтелгән иде. Үз-үзенә көч кую, тырышлык җәлеп итүне безнең рухи яктан көчсезләнгән җәмгыятебез хокук вә ирек бозу дип кабул итә. Татар теленә мәхәббәтне тәрбияләүгә багышланган телевизион тапшырулар, татар һәм рус классикларының тәрҗемәләрен бастыру, ике телдә баручы массакүләм чаралары аша тәрбияләргә ниятлиләр иде. Яңа программа кабул ителгәннән соң инде ике ел узды. Әлеге күрсәтелгән эшләрнең кайсысы тормышка ашты? Минем фикеремчә, телевидение исә бу өлкәдә үз потенциалын тиешенчә кулланмый.

26 апрель бөек шагыйребез Габдулла Тукайның туган көнендә «Үзебез» яңа буын хәрәкәте «Мин татарча сөйләшәм» дигән акция үткәреп килә. Бу башлангычка дәүләт оешмалары да кушылды.

Әлеге акция белән без татар теленең куллану даирәсе тарайган чакта яшьләрне туган телендә аралашуга өндәдек. Татар телендә сөйләшү «модалы», «кәттә» дигән фикер тудырырга тырыштык. Бу көнне шәһәр урамнарында яшьләр татар телендә сөйләшкән кешеләргә «Мин татарча сөйләшәм» дип язылган күкрәк тамгасы (значок) бүләк итеп таратып йөрделәр. Шулай ук татар телен белмәгәннәргә «Синең беренче 150 татар сүзең» дигән кыскача сүзлек тарату оештырылды. Яңа агым татар альтернатив музыка башкаручыларның концерты булды.

Бу чараны үткәрү тулаем иҗтимагый инициативага корылган. «Үзебез» - 2005 елның октябрендә яшь татар зыялылары һәм галимнәре тарафыннан оештырылган яңа буын хәрәкәте. Аның төп юнәлешләренең берсе - татар яшьләренең шәһәр мәдәниятен өйрәнү һәм аның таралыш даирәсен киңәйтү иде. «Үзебез» хәрәкәте татар мәдәнияте, сәнгате, мәгарифе, теле, туган җир табигатен саклау, яңа буын тәрбияләү проблемаларын күтәреп, аларны тагын да тирәнтенрәк анализлау һәм кичектергесез рәвештә чишүне максат итеп куйды.

Татарстан журналистлар союзы бинасында «Үзебез» Яңа буын хәрәкәте оештырган татар матбугат клубы утырышларында «татар теле язмышы» темасы гел көн үзәгендә булды.

Бөтендөнья татар конгрессы каршындагы Татар яшьләре форумында «Үзебез» яңа буын хәрәкәте координаторлары актив катнаша. Гомумән, яшьләребез ана телебезнең язмышына битараф түгел, уй-фикерләрен, тәкъдимнәрен җиткереп торалар, халкыбызны борчыган күп мәсьәләләрне уртага куеп, фикерләребезне барлап, кирәкле нәтиҗәләр ясап милләтебезнең киләчәген булдыруга үз өлешләрен кертергә әзер.

Фикеремнең асылы - законнарга гына теркәп телне үстереп булмый. Туган телебез безнең актив яклавыбызга мохтаҗ. Димәк, милли үзаңыбызның мөһим өлеше булган телебезне саклау һәм кулланышка кайтаруны без максат итеп куярга тиеш.

**РЕЗЕДА САФИУЛЛИНА**

*«Язма мирас һәм археография» фәнни-укыту үзәге җитәкчесе, Халыкара мөнәсәбәтләр, тарих һәм көнчыгышны өйрәнү институты, КФУ*

ГАЗЕТА БИТЛӘРЕНДӘ КОРЪӘНИ КӘРИМДӘГЕ АЯТЬ-СҮРӘЛӘР УРЫН АЛГАНЛЫКТАН, БАСМАГА ИГЪТИБАРЛЫ БУЛУЫГЫЗ СОРАЛА!

# Габделхак хәзрәт: ҺӘРКЕМ ҮЗ ВАЗЫЙФАСЫН БЕЛСЕН

Баш казый буларак, Габделхак хәзрәт Саматовка көн саен төрле сораулар белән мөрәҗәгать итәләр. Әмма аларның күпчелеге мәхәллә имамнары дәрәҗәсендә хәл ителә ала торган мәсьәләләр булып чыга. Арада матди ярдәм сорап килүчеләр дә очрый.

«Мондый хәлләр урыннардагы халыкның имамнар, казыйлар вазыйфасын белмәве, аңламавы сәбәпле килеп чыга» - ди баш казый үзе. Ә имамнар, казыйлар үз вазыйфаларын анык беләләрме соң? Без алдагы сораугa бәйле рәвештә Габделхак хәзрәт Саматовтан шул хакта сорадык. Ул моңа җавап итеп менә нәрсәләр әйтә:

- Иң беренчесе - һәркем үз вазыйфасына белеп керешергә тиеш. Казый, имам өстенә ниләр йөкләнгән - шуны беләсеңме? Белсәң кер. Белмәсәң тотынма. Димәк, син аны үти алмаячаксың. Менә бу мәсьәлә дини ирекка чыккач аеруча кискенләште. Белеме бармы-юкмы кеше имам булырга омтыла. Нәрсә дип уйлый? Күпчелеге шушы мәхәлләнең, авылның мулласы дигән дәрәҗә - исем алуны, икенче берәүләр шундый дәрәҗә белән мәҗлесләргә йөрүне. Мине гаепләмәгез - имамнарыбыз арасында шундый ниятлеләре дә юк түгел. Шулмы аның вазыйфасы? Аллаһ каршындагы зур җаваплылыкны аңлыймы? Имам халык өчен намазга баса да имамлык итә: кыйраәте дөресме? Ул бит шушы кешеләрнең Аллаһы каршында булган иң бөек вазыйфасын - намаз гыйбадәтен үз өстенә ала. Шунда Коръән укыла – «Фатыйха» сүрәсе, аннары янә бер сүрә. Мәгънәсен аңлыймы-юкмы, һич булмаса шуларны тәҗвид хөкеме илә укыймы? Артына оеган халык укыганына ризамы? Халык риза булмаса, аның имамәтчелеге дөрес булмый. Аны аңлыймы? Орышып, талашып, имамәтчелеккә керә. Шул дөресме? Менә боларны һәркем искә алырга, мәхәллә халкы риза булып сайлап куярга тиеш. Сайлаганда аның нәселенә түгел, ә әдәп-әхлагына карап. Яңадан гыйбадәткә әйләнеп кайтыйк: намазында рөкугъ-сәҗдәләрен җиренә җиткерәме? Пәйгамбәребез с.г.в. әйтә бит: «Шундый кешенең намазы намаз түгел, әгәр рөкугысы һәм сәҗдәләрдә умыртка сөяген төзекләп җиткермәсә». Ашык-пошык, кошлар бөртек чүпләгән шикелле борын төртеп кенә кешеләр гыйбадәтен өстенә йөкләүче шуны үти аламы, җиренә җиткерәме? Хәтта шуларга хәтле игътибарлы булырга тиеш. Җомга, гает намазларында гына булса да вәгазь сөйләнәме? Вәгазь бит ул төрлечә. Берсе Аллаһы Тәгаләнең әмер-фарызларын, вәҗибләрен, хәрәмнәрен аңлату өчен булса, икенчесе әдәп-әхлак, тормыш-хәят, гаилә, күрше мәсьәләләрендә булган темаларны аерым-аерым аңлатып бирүне күздә тота. Башкаларга үгет-нәсихәт кылган вакытта үзе шуларга үрнәк булырлыкмы? Никахны ничек укый? Ир, хатын хокукларын, ата-ана вазыйфаларын аңлатып бирә аламы?

- Алдыңмы, улым?
- Алдым.
- Бардыңмы, кызым?
- Бардым.

Моңа өстәп нәрсәдер гарәпчә укый да, шуның белән алар никахлана. Дөрес, бер өлештә бу да никахка санала, мәҗүсиләр никахы шикелле. Бит төрле никахлар бар: берсе мәҗүсиләрнеке, икенчесе социалистик никах, өченчесе -шәригатьчә. Мәсәлән, мәҗүсиләр никахына тукталыйк. Ир белән хатын бер-берсе белән килешәләр дә, бергә яшәргә тотыналар. Бер дә яшермичә, чирканмыйча бергә торалар. Берсе: «Бу минем ирем», - ди. Икенчесе: «Монысы минем хатын», - ди. Араларында фәхишәлек дип әйтеп булмый. Чөнки ир белән хатын икәнлекләрен кешеләргә белгертәләр.

Ләкин алар ЗАГСта язылмаган, никах укытылмаган. Арада ызгыш-талаш барлыкка килә башласа, аларны ЗАГС та аермый, никахлары да юк. Болар нишлиләр? Бер-берсенә: «Чык та кит»,

- диләр. Чыкты да китте. Менә шуннан гына гыйбарәт бит монысы. Икенчесе ЗАГСта теркәлгән, шаһитләре булган. Бер-берсе белән аерылышуны ЗАГС хәл кылу мөмкинлеге бар. Аннан да бөеге - Аллаһы Тәгалә исеме белән иман китереп никахлашу. Иман китергән кешеләргә генә никах уку дөрес икәнлеген аңлатып, аларга ир-хатын, ата-ана Вазыйфаларын, өсләренә йөкләнгән бурычларны төшендереп бирерлекме син? Шуларны аңлаткан соңында Аллаһы Тәгаләне шаһит итеп, шундагы кешеләрне шаһит итеп алар бер-берсенә вәгъдә бирергә



тиеш: «Мин сине үземә әманәт итеп кабул кылдым, шул әманәтне сакларга вәгъдә бирәм», -дип. Милләтебездә ул мәгънә: «Мин сине риза булып кабул кылдым», «Мин сиңа риза булып бардым» дигән рәвештә кыскартылган гына. Чын мәгънәсе аның: «Мин сине үземә әманәт итеп кабул кылдым, шушы әманәтне сакларга вәгъдә бирәм». Аңлыйбызмы шуны? Чөнки Коръән Кәримдә Аллаһы Тәгалә әманәтләрен - вәгъдәләрен хилафсыз игътибар кылып үтәүчеләрнең җәннәткә керүе хакында әйтә. Менә монда бит ул шаһитләр алдында Аллаһы исемен әйтеп Аллаһыга иман китереп вәгъдә бирә. Шул тормыш юлдашына хыянәт итәргә тиешме? Имам: «Алдыңмы, бирдеңме?» дип кенә түгел, әнә шуларны аңлатырга бурычлы, ә тегеләр бәхәсләшкән вакытта имам янына килеп: «Безнең арабызны төзәт», - дип әйткән вакытта: «Мин сөйләп үткән идем бит», - дип әйтерлек булсын. Аңлатмаган булса, тегеләр ызгышып килгән вакытта имам нәрсә дип әйтә ала? Эшкә керешкәнче бит инструктаж үткәрәләр. Инструктаж үткәрелмәсә имам ничек хөкем итә ала?

Менә имамлыкны җиңелгә санаыйбыз да, аның белән эш иткән вакытта Аллаһы каршында җавап бирәчәгебез хакында уйламыйбыз. Мәсәлән, алардан бала туа. Кинода геройны, героинямы күрәләр дә, аңа шул Альфред, Фридрих һ.б. мәҗүси исемнәрен тагалар. Пәгамбәребез ﷺ әйтә бит: «Балаларыбызга исемне матур куегыз. Кыямәт көнендә үзегезнең һәм этиләрегезнең исеме белән чакырылачаксыз», - ди. Кем моны аңлатып бирергә тиеш? «Бу исем мөселманнарга лаек түгел, балаңа андый исем куша алмыйм», - дип әйтәме? Шунда аларның хәтере калмасын өчен алар нәрсә тәкъдим иткән шуңа риза булырга тиешме имам? Бит ул көтү артыннан йөрүче түгел. Көтү имамга буйсынырга тиеш. Әнә шуңарга күрә имам да үзенекен дәлилләргә бурычлы. Баланың теле ачыла башлау белән сез аңа сүгенергә өйрәтергә түгел, «Аллаһу әкбәр», «Бисмилләһир-рахмәнир-рахим» кебек сүзләрне, иман кәлимәләрен, алты яшькә җиткәндә намаз тәртипләрен өйрәтергә бурычлы дип имам сөйләргә тиеш. Инде мәет бар икән, аны тизрәк ләхеткә илтеп тыгу гына түгел бит. Аллаһы Тәгалә каршында кемнәр без? Нәрсәгә дөньяга килдек? Шушы дөньяда кеше ниләр эшләргә тиеш? Аллаһы каршына ниләр белән барабыз? Имам җыелган халыкка Кыямәт көненең киләчәген исенә төшерергә, шул үлемнең миңа да, сиңа да киләсен танытырга тиеш. Шушы 2-3 мәсьәләдә генә булса да имамнарның Вазыйфаларын аңлыйбызмы? Менә шуларны белерлек кеше бармы? Безнең халкыбыз имамның дәрәҗәсен таныймы, имамның кем икәнлеген беләме? Имам дәрәҗәсен танымаган халык аңарга буйсынамы? Буйсынмый. Бары тик үзенең теләгенә туры килгән имамны кабул итә, үзенчә булмаганны кабул итми. Димәк, имам аның кубызына биергә тиеш. Әгәр имам аныңча булмаса, аны элеп ала, селкеп сала. Янәсе, ул имам да түгел, тегеләй-болай. Аллаһы Тәгаләнең шәригать хөкемендә дөрес барган имамга халык ияргә тиеш. Әнә бездә халык имам дип танымый, имамнарыбыз үз Вазыйфасын белми. Менә шунда низаг чыга. Шикаять белән киләләр: «Безнең имамыбыз фәләнчә, төгәнчә», - дип. Менә шуларны ачыклый башласаң, әйткәннәрнең берсе дә эшләнмәгән булып чыга. Менә шуңарга күрә имам мәҗлесләрдәме, башка урыннардамы халыкны вәгазьләргә тиеш. Мәсәлән, бүген җомга көне ди. Җомга бит ике гаеттән дә олы. Халык елына ике гаеткә бара, ә җомгага килми. Җомга олымы, гаетме? Халык белми. Чөнки атна саен килгәнгә күрә халык җомганы җиңелгә, ә Гаетне олыга саный. Аллаһы Тәгалә бит Коръән Кәримдә: «Җомга көнне Аллаһыны зекер итәргә чакыру булса, бөтен хәрәкәт, кәсепләрегезне ташлап шунда ашыгыгыз», - ди. Димәк, атна саен кеше, халык шунда имамның вәгазен тыңлап, аккумуляторный батарея заряд алган шикелле көчәеп, үзенең хата, гөнаһларына тәүбә-истигъфарлар кылып, гаиләсе, күршеләре белән атна арасында булган үпкәләрне бәхилләтергә, татулатырга, бүтән хаталарны эшләмәскә тиеш. Кайсы көн бу, кайсы ай: шул айда нинди искә ала торган көннәр бар? Менә шуның кебек эшләрне үтәгәндә, иншә Аллаһ, имамнарыбыз үзләренең өстендәге Вазыйфаларын үтәүче булыр. Халкыбыз шуларга игътибар кылып буйсынса, гадел имамнары белән укыган намазлары илә Аллаһы Тәгалә каршында булган Вазыйфаларын җиренә җиткереп үтәүчеләрдән булырлар, иншә Аллаһ. «Арагызда шундый кешеләрне булдырырга тырышыгыз, алар сезнең калебне изге эшләргә - Аллаһының кушканнарын үтәргә чакырырлар, Аллаһы тыйганнардан тыярлар. Шуңарга буйсынган, шундый имамнарны тудырган кавемнәр Кыямәт көнендә Аллаһының ачуыннан, җәһәннәм газабыннан котылучылардан булырлар», - ди бит Аллаһы Тәгалә. Имамнарыбыз тиешле вазыйфаларын үтәсә, әнә шундый сөенечләргә Ирешергә өметебез бар, иншә Аллаһ.

Инде казый дигән сүзгә килсәк, ул шәригать хөкемнәре белән хөкем итүче дигәнне аңлата. Татарстанда миннән кала тагын 6 казыят бар. Шушы казыятларның регионнарга бүленгән мәчет-имамнары бар. Имамнар хәл кыла алмаган нәрсәләрне шушы казыйлар хәл кылырга, халык казыйны белергә, аның кем икәнлеген аңларга тиеш. Казый бит матди ярдәм бирүче түгел, шәригать хөкемнәрен аңлатучы гына. Казыйларыбыз, әйтик мин баш казый, казыйлыкның бөтен өлешләрен үти аламмы дигәндә, әлбәттә, юк. Чөнки хөкүмәт бүгенге көндә андый хокукларны безгә бирмәгән әле. Мәсәлән, намаз укымаучыга 40 камчы сугарга тиеш булсам, суга аламмы? Аракы эчкән өчен 80 камчы сугарга тиеш булсам, суга аламмы? Я булмаса зина кылган кешеләргә - тормышлы булганнарына - камчы суга аламмы? Суга алмыйм. Казыйлар үти алмаган эшләр дә бар. Шулай да үгет-нәсыйхәт, вәгазь белән кешеләрне начар эшләрдән туктата алабыз. Пәйгамбәребез ﷺ: «Бер кешедә гаеп эшне күрсәгез, аны кулыгыз белән туктатыгыз, кулыгыз белән туктата алмасагыз, телегез белән туктатыгыз, телегез белән дә туктата алмасагыз, күңелегездән шуңарга рәнҗегез», -ди. Без кулыбыз белән туктата алмасак, телебез белән аны матур итеп аңлатып бирергә, араларын төзәтергә, низаглашканнарны татулаштырырга, өченче мәртәбә хатынына талак әйткән икән, аларның бер-берсенә хәрәм икәнлеген аңлатырга тиешбез. Боларны тел белән хәл кылып була. Халык төбәкләрдә үз казыйларына барырга, алардан сорарга хаклы, һәм кешеләр алар хөкем иткәнгә риза булырга тиеш.

**«Дин вә мәгыйшәт»**

НӘСЫЙХӘТ

# Мәчет әдәбе

*Дәвамы. Башы 1 нче биттә*

Мәчетләрнең төп сыйфаты аларның гыйбадәт кылу урыны булуында. Берникадәр вакытка фани дөньядан аерылып торып, ахирәт турында искә төшереп, намаз, Коръән укып, зикер әйтеп, дога кыла торган урыннар ул мәчетләр. Аллаһы Тәгаләгә гыйбадәт кыласы урынга мәчетләрдә артык сүз сөйләү ярамас. «Кем Аллаһы Тәгаләгә һәм Кыяматкә ышанса, йә күркәм сүз сөйләсен, йә дәшмәсен», ди Раббыбызның сөекле Рәсүле Мөхәммәд ﷺ (Имам Бохари һәм Имам Мөслимнең сахих хәдисләр җыентыкларыннан). Ягъни мөселман һәр җирдә, һәр вазгыятьтә теленә хуҗа булырга тиеш. Мәчеттә аеруча. Гыйбадәт кылырга килеп, дөнья мәшәкатьләрен сөйләшеп, башкаларга комачаулап утыру беребезне дә бизәми. Ун-унбиш минутка гына фанилыктан бөтенләй ваз кичеп торудан сәүдәбез дә, эшебез дә зыян күрмәс, ә гыйбадәтебезгә хилафлык китерүебез бар.

Әлбәттә, мәчетләр мөселманнарның бергә-бергә җыелышып мәхәлләнең ниндидер мәсьәләләрен хәл итү урыны. Монысы инде буш сүз түгел. Имам халыкка дөньяви мәсьәләләр илә дә мөрәҗәгать итәргә мөмкин. Мәчет тирәсен җыештыру, берәр кардәшкә ярдәм итү, ниндидер бер дини мәҗлес оештыру – болар барысы да мәхәллә әһелләренең уртага салып сөйләшә торган мәсьәләләре. Үзебезнең шәхси мәнфәгатьләребезне өммәт проблемалары белән чагыштырмыйк. Бәрәңгене базарда арзанракка саталармы, әллә кибеттәме – бу турыда башка урында да сөйләшергә була.

Гыйбадәт йортларына карата игътибарлы булу кирәк. Аллаһ Илчесе ﷺ әйтә: «Чисталык – иманның яртысы». Мөселман бәндәсе мәчет ишегалдында түгел, кешеләр йөри торган башка бер урында да, әйтик, төкереп йә йомышын үтәп китмәс. Мөселманлык мәчет өчен генә түгел. Без теләсә кайсы җирдә һәр гамәлебезне Коръән вә Сөннәт белән бәяләргә тиешбез. «Пәйгамбәребез Мөхәммәд ﷺ шулай эшләр идеме?» дип үз-үзебездән сорау бик күп хатагөнаһлардан саклар иде. Шул исәптән гыйбадәт йортларына мөнәсәбәттә. Мәчет эчендә генә түгел, аның ишегалдында да чисталык саклауга үз

ДӘВАМЫ 7 НЧЕ БИТТӘ

ГАЗЕТА БИТЛӘРЕНДӘ КОРЪӘНИ КӘРИМДӘГЕ АЯТЬ-СҮРӘЛӘР УРЫН АЛГАНЛЫКТАН, БАСМАГА ИГЪТИБАРЛЫ БУЛУЫГЫЗ СОРАЛА!

# Кол Шәриф мәчете

*Дәвамы. Башы 1 нче биттә*

Мин җитәкләгән иҗади коллектив та ул конкурста катнашты. Иң яхшы архитекторлар һәм конструкторларны берләштергән коллективыбызның эше җиңүгә иреште. Проектны тормышка ашыру процессы 9 ел дәвам итте. Безгә шактый кыенлыкларны җиңеп чыгарга, гаҗәеп күләмле эш башкарырга туры килде. Бик күп тарихи материалларны өйрәндек, мәчетләр төзү буенча бай тәҗрибәгә ия ислам илләренең архитектурасы һәм мәдәнияте белән таныштык. Ул вакыттагы президентыбыз ярдәме белән ислам илләренә эшлекле сәфәрләр оештырырга да насыйп булды. Без Төркиядә, Мисырда, Берләшкән Гарәп Әмирлекләрендә, Мароккода булдык. Андагы иң зур мәчетләрне үз күзләребез белән күрдек. Бу сәяхәтләр безне нык рухландырды. Әмма Казанда төзеләчәк мәчетне чит илләрдә күргән Аллаһ йортларына охшатып эшләү дөрес булмас иде. Чөнки һәр илнең үз традицияләре, үз тарихы. Безгә үзебезчә, татарча мәчет төзү бурычы куелды. Аллаһы Тәгалә ярдәме белән без бу эшне башкарып чыга алдык. Кол Шәриф мәчетенә кергән һәр татар кешесе мәчет бизәлешендә милли колоритны таный. Хәтта татар сәнгатеннән ерак булган кешеләргә дә ул нык сизелә. Кол Шәриф мәчете төзелешендә өч төп принципка таянып эш иттек: ислам этик нормаларын саклау, татар милли сәнгате традицияләрен күрсәтү һәм замана рухын чагылдыру».

*******

10 елга якын вакытны кәгазь битендә генә кыскача тасвирлау җиңел. Якынча 400 миллион сум тирәсенә төшкән төзелешне халык күтәреп алды. 40 меңнән артык оешма һәм шәхси зат бу изге эшкә үз өлешен кертте. Эшмәкәрләр дә, түрәләр дә, эшчеләр дә, пенсиядәге әби-бабайлар да, Кол Шәриф мәчетенең яңадан халыкка кайтарылуына өметләнеп, ярдәм итте. Гыйбадәт йортын салуга өлеш керткән һәр затның исеме шәрәфле хәйриячеләр китабына кертелгән, ул, әлбәттә, Кол Шәрифнең үзендә саклана. Шунысы сөендерә, Татарстанның күпмилләтле, күпдинле халкы бүген дә борынгы ядкарьләребезне бергә-бергә торгыза.

2005 ел. Җир шарының төрле почмакларыннан меңләгән кунак Казанга җыела. Татарстан башкаласының 1000-еллыгына зур бүләк булып, Кол Шәриф мәчете ачыла. Җыелган кешеләрнең шатлыктан аккан күз яшьләрен бөтен дөнья күргәндер. «Исламның төньяк форпосты» биш гасыр элек юк ителгән мәчетен торгызу белән мөселман даирәсендә үз дәрәҗәсен тагын да арттырды.



*******

Кем соң ул Кол Шәриф? Явыз Иван гаскәрләре Казанны яулап алган чакта җаны чыкканчы үзе имамлык иткән гыйбадәт йортын, ата-бабалары гомер кичергән туган җирен саклаган дин эшлеклесе, сәет, шагыйрь, милләтнең каһарманы, асыл улы. Яңа буыннар өчен бер калкан. Ил-көнебезгә куркыныч янаса – әзерме без шул байракны лаеклы күтәреп барырга?..

*******

2005 ел. 24 июнь. Җир шарының төрле почмакларыннан меңләгән кунак Казанга җыела. Бу көнне Татарстан башкаласында мең ярым кешелек, ишегалдында 10 меңгә якын кеше сыярлык Кол Шәриф мәчетендә беренче азан әйтелде, беренче намаз укылды.

Яңа гасыр, чыннан да, мәчетләргә яңа таләпләр куя. Бүгенге мәчет – төп вазыйфасы гыйбадәт кылу урыны булып калса да – рухи мирасны саклау, аны яңа буыннарга җиткерү эшен дә алып бара. Кол Шәриф мәчете бинасында Ислам мәдәнияте музее урнашкан. Гомуми мәйданы ярты мең квадрат метрдан артык мәйданда беренче күргәзмә 2006 елның февралендә ачыла. Төрки халыкларның дини, мәдәни ядкарьләрен саклый торган музейга Россиядә тиңнәр юк. Биредә борынгы кульязмалар, шамаильләр, әлбәттә, берничә гасыр элек язылган Коръән китапларын күреп була. Казанга килгән туристлар Кирмәнгә керми калмый. Әлбәттә, Кол Шәриф мәчетенә дә керәләр. Музейга да тукталалар. Кол Шәриф бүген Татарстанны бөтен дөньяга таныта. Шул тарихи ядкарьләр аша чит ил кунаклары безнең мәдәниятебезне өйрәнә.

Кол Шәриф мәчетендә тормышка ашырылган тагын бер үзенчәлекле проект турында да онытмыйк. Биредә һәр көн тәүлек буе Коръән-Кәрим укыла. Интернет челтәре аша турыдан-туры трансляцияне дөньяның теләсә кайсы урыныннан карап була. Бу да – дәгъвәтнең бер юлы. Мәчетне торгызуга өлеш керткән меңләгән кешенең изге эшен дәвам иттерү һәм киңәйтү.

*******

Күп кенә дини чаралар Кол Шәрифтә башлана. Никах укытырга, исем кушарга дип яшьләр, эти-әниләр Кол Шәрифкә килә. Төрле милләттән бихисап мөселман җомга, гает намазларына Кол Шәрифкә җыела.

*******

2005 ел җәендә матбугат чаралары «Казанда Европаның иң зур мәчете ачылды» хәбәрен бөтен дөньяга таратты. Ун елдан артык вакыт эчендә Татарстанда һәм Россиянең башка төбәкләрендә бик күп яңа мәчетләр салынды.

Араларында зурраклары да, күбрәк кеше сыйдыра торганнары да бар. Әмма дини яңарышның башында, илдә мөселман гыйбадәт йортларын салуда үрнәк булып нәкъ Кол Шәриф мәчете кала.

НӘСЫЙХӘТ

# Мәчет әдәбе

*Дәвамы. Башы 1 нче биттә*

өлешебезне кертү хәерле. Барысын да шушы мәхәллә имамына кайтарып калдыру дөрес булмас. Имам Тирмизи риваять кылган хәдистә әйтелә: «Үтәргә комачаулый торган таш, агач ботагы яисә сөякне алып кую – садака». Мәчеткә кергәнче үк савап алабыз.

Гыйбадәт йортларына үзебез дә, киемебез дә пакь рәвештә килү кирәк. Госелсез килеш, хатын-кызларга хәез һәм нифас халәтендә мәчеткә керү ярамас. Гомумән, Аллаһ яраткан Җир өстендә госелсез йөрү хәерле түгел. Шуның белән шайтанга үзебезгә зыян салуны җиңеләйтәбез. Раббыбыз Үзе сакласын! Мәчет турында әйтсәң дә түгел. Киемгә карата да шул ук кагыйдә. Чиста йөрү кирәк. Киемең пычранды исә – чистарту мәслихәт. «Бу мөселман кешесе һәрвакыт шундый чиста йөри», дип башкалар да кызыгырлык булырга тиеш мөэминнең тышкы кыяфәте. Мәчеткә килгәндә аеруча. Әлбәттә, төрле шартлар була. Намаз вакытын чыгармыйм, Раббым фарыз кылган гыйбадәтне вакытында үтим, дип эш киеменнән килгән кардәшләребезгә каты бәрелмәсәк иде. Киеме чиста, гаурәтен капларлык булса – кешене мәчеттән читләштермик. Матур кием киеп бару мөмкинлеге исә кулдан ычкындырмаска кирәк.

Мәчеттән читләштерү дигәннән, балаларны мәчеткә алып килүдән тыючылар бар. Аллаһ Илчесе ﷺ шулай эшләгәнме? Оныгын иңбашына утыртып намаз укытуын белмибезме? Сабый аңы бөтен нәрсәне бик тиз сеңдерә. Әгәр без баласын мәчеткә ияртеп килгән атага: «Бу баланы ник алып килдең?» дип шелтә белдерсәк, нарасыйның күңелендә «мине монда күрергә шат түгелләр» дигән фикер салуыбыз мөмкин. Аннары инде аны үскәч тә гыйбадәт йортларына китереп булмау мөмкин. Әйе, баласы белән килгән эти-әниләргә дә игътибарлы булу кирәк. Сабыйга мәчетнең, намазның нәрсә икәнен аңлату, үзеңне ничек тотарга кирәклеге турында әйтү зарур. Әлеге дә баягы мәчетне чиста тоту мәсьәләсен дә истә чыгармыйк. Ләкин, баланы өйрәтергә тотынганчы, үзебез мәчет әдәбен саклыйбызмы – шул сорауга җавап бирик.

Аллаһ Илчесе ﷺ сарымсак кебек авыздан начар ис китерә торган әйбер ашап килүдән тыйды. Яман исләрне кешеләр генә түгел, фәрештәләр дә яратмый. Хушбуй сибенүнең дә бер чиген югалтмыйк. Иңгә-иң торган кардәшебезнең гыйбадәттән игътибарын шул рәвешле читкә юнәлтмик.

Һәр хәерле эшне башлаган чакта сыман, мәчеткә уң аяктан керү сорала. Кеше бармы анда, юкмы – сәлам бирү кирәк. Әссәламегаләйкүм вә рәхмәтуллаһи вә бәрәкәтуһ! Аллаһ йортына керәбез. Анның фәрештәләрен сәламлибез. Догасын беләсең икән – берәү дә аны укудан тыймый. Бер дога мең бәладән коткарыр, ди. Мөмкинлегең бар, зәвәл, кояш чыккан яисә баткан вакыт түгел икән – мәчет намазын уку күркәм. Намазга кадәр вакыт булса – Коръән укып, зикер-тәсбих әйтү мөмкин, нәфел намазларын



кылу да хәерле. «Иртә килеп утырдым», дип хафалану кирәкмәс. Намаз уку максаты белән мәчеткә чыгып киттек исә – һәр адымыбыз өчен савап язылыр. Шуны онытып, «мәчеттән ерак яшим», дип зарланучылар бар. Мәчет каршында ук яшәп тә азанга җавап бирмәүчеләр бихисап. Шуңа да гыйбадәт кылу өчен үтелгән араның озынлыгы үзебезнең файдага гына. Һәм мәчеттә үткәрелгән һәр мизгелнең үз бәрәкәте. Җәмәгать илә намаз уку нияте белән Аллаһ йортына килүченең мәчеттә уздырган вакыты гыйбадәт кылып үткәрелгән, дип саналыр. «Җирдә иң хәерле урыннар – мәчетләр», – дип нәсыйхәтлән безне Аллаһ Илчесе ﷺ. Сәлман әл-Фәриси: «Мөмкинлегең бар икән, базарга беренче булып кермә һәм иң соңгы булып чыкма, чөнки шайтан анда сугыш алып бара һәм байрагын шунда кадап куя», дип кисәтә. Без бу сүзләргә колак салабызмы? Мәчетләр якынракмы күңелебезгә, әллә базарлар яисә башка күңел ачу урыннарымы? Күбрәк вакытыбызны кайда уздырабыз? Безгә хисап кылынганчы, үзебезгә-үзебез хисап кылыйк.

Мәчетне калдыручылардан булмасак иде. Ир-ат өчен җәмәгать белән мәчеттә намаз уку 27 тапкырга хәерләрәк, дип риваять кылына. Хатын-кызның исә намазларын өендә укуы хәерләрәк. Шулай да галимнәребез хатын-кызларга да мәчеткә баруны тыймый. Гыйлем эстәү максаты белән, әлбәттә. Тиешле рәвештә, чит ирләрнең игътибарын җәлеп иттермәслек киенеп килү дә шарт. Ә инде ирләргә мәчет әһелләреннән булырга тырышырга кирәк. Хәерле гамәлләр кылуда ярышыйк. Җомга намазына мәчеткә бару – балигълек яшенә җиткән, үз акылында булган, сәламәт һәм сәфәрдә булмаган һәр ир өчен фарыз. Имамны дикъкать илә тыңлау – җомганың бер шарты. Үтибезме? Имамны хөрмәтлибезме? Әллә җомгага да бармыйбызмы? Мәчет ишеген йә садака бирү өчен генә, йә берәр кардәшебез вафат булып, аңа җеназа укыту кирәк булгача күрә генә ачып керәбезме?..

«Кем мәчетне ярәтса, шуны Аллаһ яратыр», диелә хәдистә. Мәчетләрне яратыйк, хөрмәтлик, әдәпләрен саклыйк, шуның белән Раббыбызның сөекле бәндәләре буласыбызга ихластан ышаныйк.

ГАЗЕТА БИТЛӘРЕНДӘ КОРЪӘНИ КӘРИМДӘГЕ АЯТЬ-СҮРӘЛӘР УРЫН АЛГАНЛЫКТАН, БАСМАГА ИГЪТИБАРЛЫ БУЛУЫГЫЗ СОРАЛА!

## АКТУАЛЬ СОРАУЛАРГА ХӘНӘФИ МӘЗҺӘБЕ БУЕНЧА ҖАВАПЛАР

### – Иманның рөкеннәрен әйт.

– Аллаһы Тәгаләгә, Аның фәрештәләренә, Аның китапларына, Аның пәйгамбәрләренә, Ахирәт көненә һәм тәкъдиргә ышану.

### – Миңа Хаҗәт намазын уку тәртибен яза алмассыз микән.

– Аллаһы Тәгаләдән бер теләген тормышка ашыруны сорап, ястү намазыннан соң, 2 яки 4 рәкәгать намаз кылыныр. 1нче рәкәгатьтә «Фәтихә»дән соң өч мәртәбә «Аятел Көрси»,башка 3 рәкәгатьләрендә «Фәтихә»дән соң берәр мәртәбә «Ихлас», «Фәләкъ», «Нәс» сүрәләре укылыр. Намаз беткәннән соң Аллаһка хәмде сәнә әйтелер, хәзрәте Мөхәммәд пәйгамбәргә (сәлаллаһу галәйһи вәсәлләм) сәләтесәлам китерелер. Аннан соң бу дога укылыр:

«Лә иләһә илләллаһүл хәлимүл кәрим. Сүбеханаллаһи раббил гаршил газыйм. Әлхәмдү лилләһи раббил гәләмин. Әсъәлүкә мүҗибәти рахмәтикә үә гәзәимә мәгъфирәтикә үәл ганимәтә миң күлли бәррин. Үәссәләмәтә миң күлли исмил лә тәдәг ли зәмбә. Иллә гафәртәһү үә лә һәммән иллә фәрраҗе тәһү үә лә хәҗәтән һи йә ләкә ридан иллә кадай тәһә йә әрхәмәр рахимин".

Татарча мәгънәсе:

«Хәлим вә Кәрим булган Аллаһтан башка Илаһ юктыр. Бөек тәхетнең иясе Раббымны тәсбих итәм. Мактау галәмнең Раббысы Аллаһкадыр. Әй, Раббым! Рәхмәтеңне һәм мәгъфирәтеңне кирәкле булган һәр саваптан насыйп булуын һәм һәр гөнаһтан иминлек сорыйм. Кичерелмәгән гөнаһ, коткарылмаган кайгы, канәгатьләндерелмәгән ихтыяҗымны калдырма.

Ризалыгыңа туры килгән ихтыяҗларымны кабул ит. Әй, мәрхәмәтлеләрнең мәрхәмәтлесе булган Аллаһым!»

### – Пәйгамбәребезнең ﷺ исра кылынуы хакында әйт, кайдан кая иде?

– Мәккәдәге әл-Хәрам мәчетеннән әл-Кудстагы әл-Әкъса мәчетенә иде.

### – Пәйгамбәребезгә ﷺ беренче вахи иңгәндә ничә яшь иде?

– 40

### – Ике төрле күзгә Җәһәннәм уты кагылмас. Әйтеп бир.

– Аллаһы Тәгаләдән куркып елаган күз һәм Аллаһы Тәгалә юлында йокламыйча сакта торган күз.

### – Нинди эш иң хәерлесе?

Вакытында укылган намаз.

### – Пәйгамбәребезнең ﷺ Мәдинәгә һиҗрәт кылуында юлдашы кем иде?

– Әбү Бәкер әс-Сиддыйк (радыйаллаһу ганһү).

### – Пәйгамбәребезгә ﷺ вахи белән төшкән фәрештәнең исеме ничек?

– Җәбраил (галәйһисәләм).

### – Сүгенүгә исламда нинди хөкем?

– Үзеннән-үзе аңлашыла: сүгенү мөселманны бизәми. Пәйгамбәребез ﷺ: «Иманлы кеше сүгенми, каргымый, начар сүзләр әйтми», – дигән.

### – Ни өчен мөселманнар Мәккәдән Мәдинәгә һиҗрәт кылды?

– Ислам кабул иткәннән соң мөшрикләр тарафыннан каты иза булганга.

### – Исламның рөкеннәрен әйтегез әле.

1) «Лә иләһә илләЛлаһ, Мөхәммәд расүлүЛлаһ» – дип таныклык бирү, 2) намаз торгызу, 3) зәкят бирү, 4) Рамазанда ураза тоту, 5) хаҗ кылу.



### – Элек корбанны бер кеше исеменнән генә чала идек. Хәзер бер сарыкны ике кеше дә кушылып чала башлады. Бу дөресме?

– Әгәр корбан нияте белән сарык яки кәҗә чалына икән, ул тик бер кеше исеменнән генә чалынырга тиеш. Бер сарыкны ике кеше кушылып чалу дөрес түгел. Сарык белән кәҗә бер яшьлек булырга тиеш. Әгәр 6 айлык сарык зур булып, бер яшьлек кебек күренә икән, аны чалу дөрес.

Сыер һәм дөя төреннән булган хайваннарга җиде кеше кушылырга мөмкин. Кушылучылар мөселман булып, барысында да корбан чалу нияте булырга тиеш. Әгәр араларында берәү корбан нияте белән түгел, ә мисал өчен, ит алу өчен кушылса, беркемнең дә корбаны дөрес итеп саналмый. Сыерның — ике, дөянең исә биш яшьлек булуы шарт.

### – Исламдагы беренче мәчет ничек атала?

– Куба мәчете.

### – Корәеш кабиләсе кышын һәм җәен кайсы якларга сәфәр иткән?

– Кышын – Йәмәнгә, җәен – Шәм ягына.

**Учредитель**
Благотворительный фонд «Путь».
Газета печатается по согласованию и одобрению Муфтията Татарстана

**Редакционный совет**
Председатель – муфтий РД
Ахмад-хаджи АБДУЛАЕВ

Муфтий РТ
Камиль-хазрат САМИГУЛЛИН

Ректор Московского Исламского Института
Дамир ХАЙРЕТДИНОВ

**Главный редактор**
А. Б. МИЧИГИШЕВ

**Редактор**
Лейла ХУСЯИНОВА

**Заместитель редактора**
Фәрит БӘТИРШИН

**Канонический редактор**
Мөхәммәт РӘХИМОВ

**Литературный редактор**
Рәйсә СӘГАДИЕВА

**Отдел менеджмента**
Абдулсабир АХМЕДОВ

**Веб-версия**
Мухаммадрасул ЗАГИРОВ

**Компьютерная группа**
Ренат ИСЛАМОВ
Иса ОМАРОВ

**Индекс 35888. Подписка в любом почтовом отделении России.**
При перепечатке ссылка обязательна.
Набрано и свёрстано на компьютерной базе газеты «Ас-Салам».
Филиал ОАО «ПФОП» «Волоколамская типография»,
при участии ООО "Компания "ПРЕССА-принт"
Заказ №**5552.** Тираж **999** экз.
Подписано в печать (факт) 12.12.2016 в 14:00
(график) 12.12.2016 в 14:00
**Адрес редакции и издателя:**
367015, РД, г. Махачкала, ул. Ярагского, 128.
**E-mail:** assalamweb@gmail.com
**www.**assalam.ru
**Телефоны**
Редакция: +7-904-662-18-75 , +7-928-530-59-70
Подписка и доставка по РТ: +7-927-129-02-25
Отдел распространения по РФ: +7-926-222-78-75